# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2/ 2026

**Тасмалардан эшләнә торган бизәү алымын руслар колакка охшатып булса кирәк, «ушковая техника» дип атаганнар, шуңа ияреп «колак сыман чигү» диючеләр дә очрый. Чынлыкта исә XVIII гасырдан ук мәгълүм һәм татарларга гына хас әлеге бизәү ысулын «тырнак алмалау» дип атыйлар**







Фотолар Татарстан Республикасы Рәисе рәсми сайтыннан




# КАЗАН –
# *Ислам дөньясының мәдәни башкаласы*

Казан рәсми рәвештә 2026 елда Ислам дөньясының мәдәни башкаласы исемен алды. «Казан Экспо»да узган «Казан – Ислам дөньясының мәдәни башкаласы» елын ачу тантанасының хөрмәтле кунаклары арасында Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин, Россия мәдәният министры Ольга Любимова, Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ИСЕСКО генераль директоры Сәлим бин Мөхәммәд Әл-Мәлик, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы генераль секретаренең гуманитар, мәдәни һәм социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Тарик Али Бахит һәм башкалар бар иде.



Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм шәхсән үз исеменнән һәркемне әлеге тантана белән котлады.

Бу *«...безнең яраткан Казаныбызның да, Татарстанның да зур казанышы,* – диде ул. – *Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин билгеләп үткәнчә, Россия һәрвакыт традицион ислам кыйммәтләренә зур хөрмәт белән карый. Һәм бүген Казанны Ислам дөньясының башкаласы итеп тану – шуның дәлиле. Бу эшкә өлеш керткән барлык кунакларга һәм оештыручыларга, Рөстәм Миңнехановка һәм Россия мәдәният министры Ольга Любимовага зур рәхмәт әйтәсем килә».*

Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе җитәкчелегенә – Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга, Михаил Мишустин җитәкчелегендәге Россия Хөкүмәтенә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары – «Россия – Ислам дөньясы: КазанФорум» халыкара икътисади форумының оештыру комитеты рәисе Марат Хөснуллинга рәхмәт белдерде. *«Көчле федераль ярдәмнән башка без мондый масштабтагы чараны үткәрә алмас идек»,* – дип ассызыклады.

Сәлим бин Мөхәммәд Әл-Мәлик үзенең сәламләү чыгышында Казанны 2026 елда Ислам дөньясының мәдәни башкаласы дип билгеләп үтте, чөнки «...мондагы мәдәният музейлар һәм театрлардан тыш та яши. Казан телгә алынган саен, шәһәр гасырлар дәвамында үрелеп килгән шигырь кебек күренә. Казан елга аккан урында борынгы көй кебек тора, ә манаралар православие гөмбәзләре белән бергә аһәңле яңгыраш ала. Басма Коръән Россиягә Казаннан килгән. Бу тарихи басмалар әле дә биредә саклана», – диде ул.

# ЭЧТӘЛЕК

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ





4 **«Тере мирас»: глобальләшү чорында мәдәниятне ничек саклап калырга?**

6 **Үзбәкстанга эшлекле сәфәр**

9 **Кулдан сугылган келәм җылысы**


ШӘХЕСЛӘР




10 Г. Вәлиева-Сөләйманова **Сәнгать белеменә юлны ачучы**

18 А. Шәйхин **Бер мәкалә уңаеннан туган уйлар**


ӘДӘБИ МИРАС




24 Л. Мөхәммәтҗанова **Тарих һәм татар эпосы: Чура Нарык улы**


МУЗЕЙЛАР БУЙЛАП


28 **Кадерле ядкяр**



**Түгәрәк уен**

№2 (60) / 2026


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*

*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

**Гамәлгә куючылар:**
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәнияят өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



**Редколлегия:**
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов



**Директор:**
Алсу Равил кызы Мифтахова
**Баш мөхәррир:**
Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова

**Альманахның иҗат төркеме:**
Гөлназ Латыйпова

**Дизайнер һәм биткә салучы:**
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә (Роскомнадзор) ПИ № ФС77-79590 номеры белән теркәлгән.

Журнал өч айга бер чыга.
Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 10.06.2026.
Чыгу көне: 26.06.2026.
Заказ: № 143. Тираж: 1000 данә.

**Редакция һәм нәшер итүче:**
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Тукай ур., 74 а.
**Хатлар язар өчен адрес:**
420015, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Пушкин ур., 66/33, тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru


Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** «Тырнак алмалау» алымы белән башкарылган бизәк.
**Автор Ә. Нурхәмәтова эше.**



© «Түгәрәк уен», 2026

МИФОЛОГИК МИРАС



32 Г. Гыйльманов
**Татар аты**

КЫЙБЛА



37 А. Фәйзрахманов
**Моң илчесенең үз вазифасы**

СӘХНӘ



42 Р. Мөхәммәтова
**«Апуш»лылар татар дөньясында калачак**

ОСТАХАНӘ: «ТЫРНАК АЛМАЛАУ»



49 Р. Фаизова
**Чәчәкләрне «колагыннан» тартып**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



54 Р. Латыйпова
**Орчык өмәсе**

57 Э. Низамов,
Р. Зәйниева
**Тәнне яздыру**

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



58 Р. Фаизова
**«Шәле коймагы»**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**



# «Тере мирас»: глобальләшү чорында мәдәниятне ничек саклап калырга?



14 май көнне Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVII Халыкара икътисади форум кысаларында «Тере мирас: глобальләшү чорында мәдәниятләр диалогы – идентификациядән халыкара танылуга кадәр» дип аталган махсус сессия узды. Әлеге чараның Уникаль һөнәрчелек үзәгендә (ЦУМ) узуы очраклы түгел, чөнки ул – халык һөнәрчелегенең 17 юнәлешен эченә алган 68 остаханәне һәм 79 резидентны, ягъни Республиканың мәдәни мирасы сагында торучыларны берләштергән урын.

Сессияне В.Д. Поленов исемендәге Россия дәүләт рус халык иҗаты йорты директоры, ЮНЕСКО эшләре буенча Россия Федерациясе комиссиясе әгъзасы һәм РФ Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр буенча совет әгъзасы Тамара Валентиновна Пуртова алып барды.

Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре

Алсу Равилевна Мифтахова катнашучыларга сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте.



Сессиядә катнашучылар ислам дөньясының матди булмаган этномәдәни мирас объектларының җирле танылудан башлап ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертүгә кадәр юлны ничек үтәргә дигән мәсьәләгә һәрьяклап якын килделәр. Фикер алышу стратегияләрне, практик чишелеш юлларын һәм төрле илләрнең тәҗрибәләрен берләштерүгә юнәлтелде.

Сессиядә Мәскәүдән Тамара Пуртова («Традицион кыйммәтләрне саклау һәм милләтара татулыкны ныгытуда ресурс буларак Россиянең этномәдәни мирасы»); Үзбәкстаннан онлайн презентация белән Роберт Әлмиев («ЮНЕСКО исемлегенә матди булмаган мирасны кертү практикасы»); Пермьнән Россия Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Александр Черных («Матди булмаган этномәдәни мирасны өйрәнү һәм яңарту тәҗрибәсе»); Кыргызстаннан филология фәннәре докторы, манасчы Талантаалы Бакчиев («Манас» эпосында ислам пәйгамбәрләрен бәян итү»); Шәһәрләр һәм җирле үзидарәләр Бөтендөнья оешмасының Евразия бүлеге генераль сәркатибе Расих Сәгыйтов («Евразия шәһәрләрендә ЮНЕСКО мирасын саклау тәҗрибәсе һәм халыкара башлангычлар»); ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының геомәгълүмат технологияләре бүлеге җитәкчесе, техник фәннәр кандидаты Гүзәл Сәйфетдинова («Халыкара мирасны тануда Татарстан тәҗрибәсе») чыгыш ясадылар.

Махсус сессия мирасның сакланып калуы белән бәррәттән, аның эшлекле аралашу һәм халыкара танылу өчен нигез булып торуын күрсәтте.






# Үзбәкстанга эшлекле сәфәр

3 – 7 апрель көннәрендә Татарстан делегациясе мәдәният өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу өчен Үзбәкстанның әйдәп баручы мәдәни үзәкләрендә булып кайтты. Сәфәрнең төп максаты – мәдәният үсешендә булган яңалыклар, халык иҗатының сакланышы белән танышу.

Сәфәрнең беренче көне Фирганә өлкәсенең мәдәни һәм җитештерү объектлары белән танышуга багышланды. Маргилан шәһәрендә делегация Үзбәкстанның ефәк һәм киҗе-мамык тукымалар җитештерү буенча махсуслашкан иң эре предприятиеләренең берсе – «Ёдгорлик» фабрикасында булды. Биредә кунаклар, тукыма ясауның ефәк кузысын табудан һәм эшкәртүдән башлап, табигый буяуларга ману һәм традицион станнарда кулдан тукуга кадәр булган тулы циклы белән таныштылар.

Шулай ук Маргилан шәһәренең 8 нче, 10 нчы балалар музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә, Фирганә өлкә китапханәсендә (китапханә һәм мәгълүмат үзәге) булдылар. Китапханәдә делегациягә фондларны цифрлаштыруның заманча ысуллары һәм төрле категория китап укучыларга уңай мәгълүмати мохит булдыру белән таныштылар.

Сәфәр барышында «Мәхәллә» институты – Үзбәкстанның территориаль-административ берәмлеге (кечкенә бер территориядә яшәүчеләрне берләштерүче җәмгыять) белән таныштыруга зур игътибар бирелде.

Беренче көн программасын йомгаклап делегация Йосыф-Кизик Шәкәрҗанов исемендәге Фирганә өлкә музыкаль драма театрына юл алды.

* * *

Икенче көн район дәрәҗәсендәге мәдәният белән идарә итү системасы; традицион һөнәрчелек; Фирганә өлкәсенең архитектура һәм тарихи мирасы белән танышуга багышланды.

Визит Алтыарык районы мәдәният бүлегенә барудан башланды.

Программаның мөһим өлеше Риштан районындагы һөнәрчеләр үзәгенә, шулай ук төбәктәге әйдәп баручы керәч (керамика) үзәкләренең берсе булган «Mingboshi Ceramic» гаилә остаханәсенә бару булды. Анда Риштан керамикасының гасырлар буена дәвам иткән традицияләре кадерләп саклана. Делегациягә җитештерүнең җирле балчыктан кул белән калыплаудан алып легендар «ишкор» глазурен куллану һәм кул белән







бизәк төшерүгә кадәр булган тулы циклы күрсәтелде.

Татарстан кунаклары Үзбәкстан Республикасының мәшһүр декоратив-гамәли сәнгать осталары, Халык һөнәрчеләренең «Һөнәрмәнд» ассоциациясе әгъзалары Үзбәкстан Республикасы Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы Рөстәм Усманов һәм Үзбәкстан Республикасы Сәнгать академиясе әгъзасы һәм Халыкара керамика үзәге директоры Алишер Назиров остаханәләрендә булды.

Һөнәрчелек серләрен буыннан-буынга тапшыруга нигезләнгән гаилә бизнесы бер үк вакытта матди булмаган мәдәни мирасны саклау, туристларны җәлеп итү, эш урыннары булдыру кебек проблемаларны хәл итә алуын да күрсәтте. «Мәхәллә» проекты кысаларында һөнәрчелек кластерлары актив үсештә булган Татарстан өчен Риштан чүлмәкчеләренең җитештерү процессын оештыруы һәм яшьләргә традицион техниканы өйрәтү тәҗрибәсе аеруча кыйммәтле.

Делегацияне архитектура һәйкәлләре, шул исәптән Урта Азия архитектура стиленең ачык үрнәге булган Коканд ханлыгының соңгы хакиме өчен төзелгән җиденче хан сарае – Аллаһыяр хан сарае таң калдырды.

Мондый объектларны саклау һәм музейга әйләндерү тәҗрибәсен өйрәнү, шул исәптән аларны заманча куллануга җайлаштыру, экскурсияләр оештыру Татарстандагы тарихи һәм архитектура һәйкәлләре белән эшләү өчен дә файдалы.

Икенче көнгә планлаштырылган программаның мәдәни өлеше Үзбәкстандагы иң зур дини комплексларның берсе, милли әһәмияткә ия ислам мәдәни һәйкәле булган гамәлдәге Җәмигъ мәчетенә бару белән тәмамланды.

* * *

Татарстан делегациясенең Үзбәкстандагы өченче көнендә дәүләт гамәли сәнгать музее, Ислам цивилизациясе үзәге һәм Милли сәнгать үзәгенә бару каралган иде.

Үзбәкстан дәүләт гамәли сәнгать музее илнең иң мөһим мәдәни учреждениеләренең берсе, анда халык һөнәрчелеге һәм декоратив гамәли сәнгатьнең бай мирасын күрергә була. Музей тупланмасында меңләгән экспонат саклана, XIX гасырда һөнәрчеләр тарафыннан кулланылган сирәк эскизлар архивы, орнамент схемалары һәм буяу үрнәкләре аеруча кыйммәтле.

Биредә әзер продуктларны күрсәтеп кенә калмыйча, технологик процессны, эш коралларын, эскизларны һәм материалларны күрсәтүгә дә басым ясала һәм бу һөнәрчелек традицияләрен тирәнтен аңларга мөмкинлек бирә.

Президент Шәүкәт Мирзиёев башлангычында булдырылган Ислам цивилизациясе үзәге – төбәктә уникаль комплекс. Ул музей, фәнни-тикшеренү комплексы, китапханә, халыкара партнерлар структуралары, фәнни лабораторияләр һәм белем бирү бүлекләрен берләштерә. Делегация үзәкнең концепциясе, күргәзмә мәйданнары һәм фәнни эшчәнлеге белән танышты.

Ташкенттагы традицион милли һөнәрчелек һәм гореф-гадәтләрне саклап калу һәм популярлаштыру максатында төзелгән Милли сәнгать үзәгенә бару. Татарстанның уңышлы тәҗрибәсе контекстында аеруча әһәмиятле. «Мәхәллә» проекты Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла, аның максаты – этномәдәни төрлелекне, халык сәнгатен, матди булмаган мәдәни мирасны һәм традицион гаилә һәм рухи кыйммәтләрне саклауга ярдәм итүче мәдәни ял итү урыннарын үстерү.

Бүгенге көндә «Мәхәллә»нең иҗади киңлекләре республиканың 28 муниципаль районында эшли. 2024 елда әлеге проект Арча, Апас, Чүпрәле, Кукмара, Мөслим, Балык Бистәсе һәм Саба районнарында башланды. Бер ел дигәндә аларга тагын Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Балтач, Бөгелмә, Биектау, Мамадыш, Тәтеш һәм Чирмешән районнары кушылды.

2026 елда проектның географиясе киңәюен дәвам итте – Әтнә, Буа, Алабуга, Яшел Үзән, Кайбыч, Лениногорск, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман һәм Чистай районнары өстәлде.

Проект чигү, киез басу, агач кисү, чүлмәк ясау, туку, келәм чигү, бәйләү, традицион баш киемнәре эшләү һәм һөнәрчелекнең башка остаханәләрен үз эченә ала.

Милли сәнгать үзәге белән эшләү делегациягә һөнәрчелек кластерларын оештыруның альтернатив модельләрен, яшьләрне җәлеп итү ысулларын һәм халык сәнгате продуктларының асылына зыян китермичә коммерцияләштерү юлларын өйрәнергә мөмкинлек бирде, бу исә Татарстанда «Мәхәллә» проектын алга таба үстерү өчен файдалы булырга мөмкин. Шулай итеп, сәяхәтнең өченче һәм соңгы көне Татарстан делегациясенә гамәли сәнгать өлкәсендәге конкрет күргәзмә чишелешләреннән алып, зур фәнни һәм мәдәни үзәкләр булдыруга стратегик якын килү һәм заманча шәһәр контекстында традицион һөнәрчелекне хуплау өчен бай ризык бирде.



# Кулдан сугылган келәм җылысы

Россия халыклары бердәмлеге һәм Татарстан Республикасында хәрби һәм хезмәт батырлыгы елына багышлап уздырылган «Җепләр бердәмлеге – хезмәт горурлыгы» дип аталган төбәкара конкурсның җиңүчеләре билгеле булды. Тукучыларны бүләкләү тантанасы Лаеш районы Никольское авылында уза торган «Каравон» рус халык фестивале кысаларында үтте. Бәйрәм кунаклары кулдан тукылган келәмнәр күргәзмәсе белән танышты һәм көн дәвамында келәмчелекнең серләренә төшендерүче осталык дәресләрендә катнашты.

*– Бәйгегә кулдан тукылган 80 эш кабул иттек, шуларның 75 е сайлап алынып, икенче турга узды. Милли традицияләрне чагылдыру, электән килгән техника һәм бизәкләрне куллану, буыннар арасындагы дәвамчанлык, сәнгатьчә башкару һәм милли мираска иҗади яңа караш – эшләргә бәя биргәндә сәнгать белгечләреннән торган жюри эшләнмәләрнең нәкъ менә шул таләпләргә туры килү-килмәвеннән чыгып үз сүзен әйтте,* – ди Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты һәм әлеге проектның кураторы Наталья Веретенникова.

Бәйге халкыбызның милли гореф-гадәтләре бүген дә дәвам итүен, һөнәрчелекнең бу тирән яшь буынга түкми-чәчми тапшыручылар барлыгын күрсәтте. Осталар «профессионаллар» һәм «һәвәскәрләр» арасында җиде номинациядә билгеләп үтелде.

«Гореф-гадәтләр» номинациясенең «профессионал» категориясендә – Наталья Уразгильдина («Мирас» келәме);

«Юлга ак җәймә» номинациясенең «профессионал» категориясендә – Ләйлә Галимова («Күзгә күеф» келәме) һәм Гүзәл Зарипова («Якты полосалар» паласы); «һәвәскәр» категориясендә – Ольга Деревянко («Язгы күк» идән паласы);

«Бизәкле мозаика» номинациясенең «профессионал» категориясендә – Гүзәл Мостафина («Ялтыравык» келәме) һәм Гүзәл Вәлитова («Куш бадыян» асалы паласы); «һәвәскәр» категориясендә – Марианна Абрамова («Удмурт калейдоскобы» келәме);

«Тукылган билбау» номинациясенең «профессионал» категориясендә – Елена Корезина (Алабуга музеендагы билбауның реконструкциясе); «һәвәскәр» категориясендә – Елена Смирнова («Әрекмән бәхет эләктерә»);

«Традицияләрнең заманча укылышы» номинациясенең «профессионал» категориясендә – Елена Егорова («Медитация» күлмәге) һәм Гөлчәчәк Гатина («Су анасы» гобелены); «һәвәскәр» категориясендә – Татьяна Зиннәтуллина («Полюшко-поле» панно);

«Төкле (ворслы) бизәкләр» номинациясенең «һәвәскәр» категориясендә – Рәисә Хәйрединова («Анарлар» панносы) һәм икесенә бер урынны бүлешкән Валентина Винтилина белән Гүзәл Хәйруллина («Бизәкләр дөньясы» һәм «Бизәктән илһам алып» келәмнәре).

«Яшь тукучылар» номинациясенең һәвәскәрләр категориясендә – Руфина Гафурова («Шатлык» келәме) һәм Анна Зиманова («Гореф-гадәтләрне торгызу») панносы җиңү яуладылар.

Җиңүчеләрне котлыйбыз!



Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
*сәнгать фәннәре докторы,*
*профессор*



# *Сәнгать белемендә* ЮЛНЫ АЧУЧЫ

*Фуад Вәлиевнең академик хезмәтләре тарих, сәнгать, этнография һәм археология киселеше күзлегеннән языла*

2026 елның 15 маенда күренекле галим, татар сәнгать белемендә нигез салучы һәм Идел буенда беренче сәнгать белеме докторы Фуад Хәсән улы (Хөсәен) Вәлиевнең тууына 105 ел тула. Аның хезмәтләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган, ул – гаять бай фәнни һәм иҗади мирас калдырган шәхес.

Рәссамнар һәм архитекторларның, халык һөнәрчеләренең заманча эш-гамәлләре һәм иҗатлары өчен, аның үз рәсемнәре һәм фотосурәтләре кергән китаплары аеруча файдалы, чөнки аларда татар бизәкләре һәм декоратив-гамәли сәнгатькә караган материаллар тарихи күзлектән гомумиләштерелеп бирелә. Фуад Вәлиевнең монографияләре, китаплары, фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре, меңләгән рәсемнәре, төгәл үлчәмнәре бирелгән сызымнары һәм фотосурәтләре сәнгать тарихы, этнография, археология һәм тарих өлкәләрендәге тикшеренүләр өчен фәнни нигез һәм тиңе булмаган чыганак булып хезмәт итә. Принципиаль һәм гадел галим буларак, ул үзенең идеяләре, ачышлары, кылган гамәлләре белән абруй казанды. Аның биографиясе дә XX гасырдагы күп кенә совет галимнәре һәм мәдәният эшлеклеләренең авыр язмышлары белән аваздаш.

**Вәлиев Ф.Х.**
**1950 еллар**



**Вәлиевләр гаиләсе Мәскәүдә. Сулдан: утырган һәм басып торучылар – әти-әнисе һәм ике кыз туганы. Идәндә сулдан – Ф. Вәлиев**

## НӘСЕЛ-НӘСӘП ЯКЛАРЫ

Фуад Вәлиев 1921 елда Мәскәүдә туа һәм 1984 елның 11 октябрендә Казанда вафат була. Әтисе Хөсәен Вәлиев Кече Кавал авылында (хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районы) данлыклы күнчеләр нәселеннән булган гаиләдә туып үскән. 1920 елларда ул Мәскәүгә килеп төпләнә һәм тукыма фабрикалары тота. Әнисе Нәгыймә Мәһдиева – Кече Кавал мәчетенең имамы, тумышы белән Чистай өязе Шахмай авылы тумасы Шәйхетдин Гайнетдиновның кызы. Шәйхетдин җәдитчә укыткан һәм аның туганлык җепләре әнисе ягыннан Гаяз Исхакыйга барып тоташа. Фуад Вәлиевнең әбисе Мәгыйзҗан Сәлимова – сигез буын дәвамында атадан улга күчә килгән муллалар, мөгаллимнәр нәселеннән булган Сәлимҗановлар гаиләсеннән. Алар күрше Әлдермеш авылының беренче мәхәлләсендә халыкны дингә өндәгәннәр. Гаилә башта Кече Кавалда, 1920 елдан соң Мәскәүдә яши. Булачак галим дә, әйткәнемчә, шунда дөньяга аваз сала. 1928 елда, Фуадның әтисе, беренче тапкыр кулга алынып, Барнаул янындагы Сталин лагерена сөргенгә озатылганнан соң, торыр урыны һәм яшәү өчен матди мөмкинлеге калмаган гаиләсе Казанга кайтырга мәҗбүр була. 1937 елда репрессия корбаны буларак атып үтерелгән (ул Казанның Архангель зиратында җирләнгән) Хөсәен Вәлиевнең исеме 30 елдан соң гына аклана.

## ЭЗЛӘНҮЛӘР, ТАБЫШЛАР

Фуад урта мәктәпне Казанда тәмамлый. Укуын Киев төзелеш инженерлык институтында дәвам итә, чөнки «халык дошманы» улы буларак, аңа Казанда югары уку йортларына керү юлы ябыла. Сугыш башланып, Киевны тупка тота башлагач, ул контузия ала һәм Ташкентка

эвакуацияләнә. Сугыштан соң 1947 елны Киев институтын тәмамлаган Ф. Вәлиев инженер-архитектор дипломы белән Казанга кайта. 1947–1957 елларда ул «Татгипронефтьпроект» институтының проектлау бүлеген җитәкли. Казанда (Татарстан АССР Халык хуҗалыгы күргәзмәсе павильоннары), Әлмәт һәм Бөгелмәдә берничә зур җәмәгать корылмаларының проектларын ясый. Фуад Хәсәнович – Горький паркындагы Г. Тукай һәйкәленең (1955) архитекторы (скульпторы И.А. Новосёлов), Казанда югары класслы ательеның эчке бизәлеш авторы да ул. 1957–1959 елларда ул Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Махсус фәнни реставрация остаханәләренең баш архитекторы һәм фәнни бүлек җитәкчесе вазифаларын башкара. Ф.Вәлиев – Болгар шәһәрлеге (Болгар тарихи-архитектура тыюлыгы) һәйкәлләре, аерым алганда, Кара пулат, Кече Манара һәм төрбәләрне реставрацияләү проектлары авторы.

Ул СССР Архитекторлар берлегенең иң тәүге әгъзаларының берсе иде, 1950 еллар ахырында Казандагы Мәрҗани мәчете бинасын проектлап аны киңәйтергә омтылган өчен, ул гаделсез рәвештә берлектән чыгарыла.

Казан тарихчылары Н.Ф. Калинин һәм Н.И. Воробьёв чакыруы буенча, элеккеге архитектор СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керә, ә 1959 елдан этнография бүлегендә фәнни хезмәткәр була. Монда ул үзенең беренче фәнни эшен, «XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан татарларының милли орнаментлары»н әзерли һәм 1966 елда аны Мәскәүнең Миклухо-Маклай исемендәге Этнография институтында яклап, тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Шул ук елны Тел, әдәбият һәм тарих институтында сәнгать бүлеге ачыла, һәм ул анда 1969 елга кадәр хезмәт куя.

## ГЫЙЛЕМ БЕЛӘН ГАМӘЛ БЕРЛЕГЕ

1971 елда галим Казаннан китәргә мәҗбүр була һәм 1981 елга кадәр Мари политехника институты чакыруы буенча шунда укыта. Йошкар-Олада ул үзенең фәнни хезмәтләрен – «Урта



**XV—XVI гасырларда Хан сараена керешли Казан Кремле һәм Кол Шәриф мәчетенең сурәте. 1980 ел**

Идел буеның борынгы һәм урта гасыр сәнгате» һәм «Казан татарларының архитектура һәм декоратив сәнгате (авыл йортлары)»н бастырып чыгару мөмкинлегенә ия булды (1975 ел) һәм шунда ук XVIII – XX гасыр башлары материалларына нигезләнеп, «Казан татарларының милли декоратив сәнгате, аның килеп чыгышы һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясен әзерли. Ул аны 1982 елда Мәскәүдә СССР Сәнгать академиясенең Сынлы сәнгать тарихы һәм теориясе фәнни-тикшеренү институтында яклый. Шуннан соң Казанга кайта һәм СССР Сәнгать академиясе тәкъдиме буенча, «Идел буендагы бердәнбер сәнгать тарихы докторы» буларак, 1981 елда Татарстан АССР Куллanучылар хезмәте министрлыгының баш рәссамы итеп билгеләнә. 1982 – 1984 елларда Ф. Вәлиев Татарстан АССР Җирле сәнәгать министрлыгының фәнни консультанты булып эшли. 1984 елда Казанда Ф.Х. Вәлиевнең исән чагында язган «Татарстанның халык декоратив сәнгате» дигән соңгы хезмәте басылып чыкты (2020 елда кыскартуларсыз кабат басылды). «Татарстанның борынгы сәнгате: борынгы


*Фуад Вәлиев кабинет саклап утыручы галим булмады. Ул мәдәниятнең төрле өлкәләренә, шул исәптән музей эшен үстерүгә дә үзеннән зур өлеш кертте. Экспедицияләр вакытында җыйган материаллары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның татар кулланма гамәли сәнгате тупланмасының нигезен тәшкил итте.*



**Идел буенда**



**Фуад Вәлиев Болгарда казу эшләре вакытында**



заманнардан XVI гасыр уртасына кадәр» дигән хезмәте исә аның вафатыннан соң 1986 елда басылып чыга һәм 2002 елда (кызы Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова тырышлыгы белән – *ред.*) кабат дөнья күрә.

Фуад Вәлиев – бүгенгәчә республикада татар халык декоратив сәнгате тарихын Борынгы төрки һәм Болгар чорыннан башлап тасвирлаган һәм эволюция үсешен комплексны өйрәнгән бердәнбер галим. Аның хезмәтләрендә XVIII гасыр – XX гасыр башындагы татар сәнгате, болгар һәм татар бизәкләре, кабер ташларында һәм архитектурада ташны уеп бизәү, торак-йортларны бизәүдәге уемчылык, каюлы кун, чигү, тукучылык, келәмчелек, алтын белән чигү, зәргәрчелек һәм шәмаил турында җентекләп язылган. Ул үзенең тикшеренүләрен киң фактик һәм иллюстратив материаллар – архитектура һәйкәлләренең үз үлчәмнәре, кабер ташларының фотосурәтләре, сәнгать әсәрләренең график эскизлары, төсле (акварель, гуашь) һәм аклы каралы (кара, карандаш) рәсемнәр, таблицалар һәм схемалар белән тулыландырды, ныгытты. Аның меңләгән сәнгать әсәрләрен, архитектура һәйкәлләрен, Казан, Касыйм, Кырым һәм Әстерхан татарларының-һөнәрчеләренең кул эшләнмәләрен чагылдырган фотосурәтләрдән торган тупланмасы Татарстан, Чувашстан, Марий Эль, Мордовия, Удмуртия, Башкортстан, Рязань һәм Әстерхан



**XX гасыр башында татар йортының капкасын бизәү үрнәге. Казан арты**

**Агач уеп ясаган бизәк үрнәкләре. Казан арты**



**Сафагәрәй кабере өстендәге Сөембикә портреты. Автор аны үзе агачны уеп ясаган бизәкле рамга урнаштырган. Катыргы, тушь, агач, ДВП. 1980 еллар**

өлкәләре авылларында, шулай ук Кырымда (Бакчасарай, Солхат, Евпатория, Феодосия) узган 30 еллык экспедицияләренең елъязмасы булып тора.

Галим үзенең хезмәтләрен татар сәнгате тарихы белән кызыксынучы галимнәр яки укучылар өчен генә иҗат итмәгән. Китапларында тупланган материалларның татар мәдәниятенә хезмәт итүче иҗади шәхесләргә файда китерәчәгенә ул һәрвакыт инанып яши. Тарихи жанрдагы картиналар иҗат итүче рәссамнар булсынмы ул, татар риваятьләрен һәм гореф-гадәтләрен сурәтләүче графиклармы, чорны һәм шәхесне сурәтләүче сынчылармы, биналарны бизәүче яки милли киңлекләр-мәйданчыклар булдыручы дизайнерлар һәм архитекторлармы... Ф. Вәлиев заманча милли сәнгатьне үстерү өчен иң беренче чиратта аның традицияләрен, стиль, җитештерү технологияләрен һәм бизәлеш үзенчәлекләрен ачып бирү зарурлыгын аңлап эшләгән. Болар һәммәсе Болгар чорыннан ук килеп, гасырлар дәвамында үзгәрешләр кичерүче татар сәнгатенең һәм анда булган традицияләрнең заманча рәссамнар иҗатында ни рәвешле үзгәреп, ныгып калуын күрергә мөмкинлек бирә. Фуад Вәлиев китапларыннан алынган материаллар 1960нчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр күп кенә күренекле татар рәссамнары һәм декоратив-тасвири сәнгать осталарының иҗатына зур йогынты ясады. «Казан татарлары орнаменты» (1969) китабы һәм авторның рәсемнәре тупланган альбом белән кабат бастырылган «Татар халык орнаменты»ның (2002) дизайнерлар, рәссамнар, архитекторлар һәм халык сәнгате һөнәрчеләре өчен үзенчәлекле өстәл китабына әверелүе бәхәссез.

Фуад Вәлиев кабинет саклап утыручы галим булмады. Ул мәдәниятнең төрле өлкәләренә, шул исәптән музей эшен үстерүгә дә үзеннән зур өлеш кертте. Экспедицияләр вакытында җыйган материаллары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның татар кулланма гамәли сәнгате тупланмасының нигезен тәшкил итте.

## ХАЛЫК ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕН ҮСТЕРҮ ХАКЫНА

Ул үзенең иҗади егәрен, белемен Татарстанда халык һөнәрчелеген һәм милли сувенирлар җитештерүне торгызуга багышлады. Татарстан АССР Кулланучылар хезмәте министрлыгының баш рәссамы һәм Җирле сәнәгать министрлыгының консультанты буларак бу эшләрдә турыдан-туры катнашты. Фуад Вәлиев Казан халык сәнгате һөнәрләре комбинатында сувенир җитештерү цехларын һәм Казан өйдә эшләүчеләр фабрикасын оештыруда катнаша. Саба районының Шәмәрдән бистәсендә көмеш бизәнү әйберләре җитештерү остаханәсе шулай ук аның тырышлыгы, үҗәтлеге нәтиҗәсе буларак оеша. Ул үзе әйберләрнең эскизларын ясый һәм осталарны өйрәтә, алар белән бергәләп иҗади идеяләрне тормышка ашыра. Аның реконструкцияләре һәм эскизлары буенча милли бизәнү әйберләре, агач эшләнмәләр, керәч (керамика) һ.б. иҗат ителде; Иске Казан музей-тыюлыгы өчен Әтнә, Миңгәр кебек Казан арты авылларындагы XVIII һәм XIX гасырга караган агач йортларының макетлары ясалды. Фуад Вәлиев эскизлары буенча рәссам Б. Шубин тарафыннан башкарылган Алтын Урда чорына кадәрге Идел буе Болгарста-



Болгар керәч савыты, X–XII гасырлар. Реконструкция. Рәссам Б. Шубин башкаруында. 1980 еллар



Болгар көзгесендәге рәсемгә нигезләнеп агачны көйдереп ясалган 1980 еллар

*Фуад Вәлиев – бүгенгәчә республикада татар халык декоратив сәнгате тарихын Борынгы төрки һәм Болгар чорыннан башлап тасвирлаган һәм эволюция үсешен комплекслы өйрәнгән бердәнбер галим*

ны һәм Казан ханлыгы чорындагы керәч сәнгатен чагылдыручы савыт-саба үрнәкләре исә бүгенге көндә Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музее тупланмасында саклана. Фуад Вәлиев сувенирларда һәм бүләк-санак өчен җитештерелгән эшләнмәләрдә татар бизәкләрен куллануның яңа мөмкинлекләрен ачты. Иҗади шәхес булырак, ул үзе дә төрле юнәлештә иҗат итте – агачка яндырма рәсемнәр һәм төрле тестәге бизәкләр төшерелгән дивар тәлинкәләре, агачтан һәм каен тузын буяп ясаган сувенир эшләнмәләре шуңа дәлил булып тора. Ул үзенең «Сөембикә» картинасында (гуашь, тушь, 1974) Казан ханбикәсенең образын беренчеләрдән булып гәүдәләндерә. Аның таланты шулай ук татар музыкасын иҗат итүдә дә чагылыш тапты. Архивта 1968 елда фортепиано өчен эшкәртелгән «Моң», «Уйлану», «Вальс» кебек музыкаль пьесалары һәм башка композицияләре саклана.

Фуад Вәлиевнең татар сәнгатенә керткән өлеше галимнең вафатыннан соң объектив бәя алды. 1991 елдан башлап, ТР Фәннәр академиясе һәр биш ел саен галим истәлегенә багышлап халыкара фәнни конференцияләр – «Вәлиев укулары»н оештыра. Күп еллар дәвам иткән тыюлардан соң «Беренче Вәлиев укулары» кысаларында, Алтын Урда тарихын өйрәнү проблемалары буенча тәүге тапкыр Халыкара түгәрәк өстәл үткәрелде. 2021 елда, галимнең тууына 100 ел тулу уңаеннан, «Алтынчы Вәлиев укулары» югары дәрәҗәдә оештырылды. Аның кысаларында халыкара фәнни конференция, түгәрәк өстәл оештырылды һәм «Хәзинә» милли сәнгать галереясында декоратив-кулланма гамәли сәнгать күргәзмәсе ачылды.





Айдар ШӘЙХИН,
*Татарстан Милли музее филиалы – Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камалның мемориаль фатиры мөдире, КФУ диннәрне өйрәнү кафедрасының өлкән укытучысы*

*Атаклы археограф һәм мөгаллимә Зәйнәп Габделҗәмил кызы Максудова (1897–1980) гомерен мөселман китап мирасын туплауга, саклауга һәм тасвирлауга багышлаган.*

*Рәсми фәнни институтларда эшләмәсә дә, ул берүзе тулы бер оешма башкарырдай хезмәтне үтәп чыга, кулъязмалар туплау буенча оештырылган экспедицияләрнең алыштыргысыз киңәшчесенә, «рәсми исемле» галимнәр өчен абруйлы шәхескә әверелә. Аның искиткеч бай китапханәсе һәм архивының шактый өлеше 1980 елдан соң хәзерге Татарстан Милли музеена тапшырыла. 2020 елда Әлфрид Бостанов тарафыннан төзелгән «Зәйнәп Максудова китапханәсе» исемле каталог дөнья күрде.*

# Бер мәкалә уңаеннан туган уйлар

*Музейда саклanган Зәйнәп Максудова тупланмасында аның китапханәсенә кергән, ул тасвирлаган китаплардан тыш, галимәнең кулъязмада калган мәкаләләре дә бар. Шундый язмаларның берсе – «XIX гасыр татар мәдрәсәләрендә шигырь сәнгате белән мавыгучылар» дип аталган мәкалә. Мәгълүм ки, Максудованың гомерлек эше – татарларның интеллектуаль шәҗәрәсен, мәгърифәт үзәкләренең һәм гыйлем-тәрбия таратучыларның тарихларын, кемнән һәм кайда белем алуларын, китапларның кайда, кем тарафыннан язылуын, күчереп алынуын һ.б. туплау. Бу мәкаләдә Габдеррәхим исемле шагыйрь искә алына һәм аның иҗатына мисал рәвешендә үзе күчереп язган «Гавамил» китабының ахырында теркәлгән шигырь китерелә.*

*Сезнең игътибарыгызга Зәйнәп Максудованың бу мәкаләсен әдәбият-китап тарихын өйрәнү фәненең бер ядкяре буларак тәкъдим итәбез. Язманың ахырында галимә туплаган фактларга бәйле кайбер шәрехләр һәм фикерләр белән дә уртаклашабыз.*

Зәйнәп Максудова

# XIX гасыр татар мәдрәсәләрендә шигырь сәнгате белән мавыгучылар

## *Габдеррәхим шагыйрь һәм аның иҗат үрнәге*

Актаныш ягы Иске Әлем авылында бик борынгы заманнардан ук үз вакытына күрә яхшы гына уку йортлары яшәп килгән. Мәсәлән, анда 1835 елларда шактый күренекле мәдрәсә булып, анда Яхшыкол Җомагол углы дигән мөдәррис дәрес биргән, шәкертләр тәрбия кылган. Бу кеше замандашлары арасында тирәнрәк белеме, укытуда гаять тырыш һәм ихласлы булуы белән танылган. Бу мөдәррис үзенең укучыларына Коръән, хәдис, фикъһ кебек гыйлемнәр белән бергә гарәп, фарсы, төрек телләре һәм әдәбиятларын да өйрәткән, хәтта фәраиз гыйлеменә баглап, җәбер, һәндәсә фәннәреннән дә беркадәр өлеш биргән. Шуңар күрә аны укучылары ихтирам иткәннәр, биргән дәресләрен нык үзләштерергә тырышканнар. Гаруз, кафия кагыйдәләре буенча күнегүләр ясап, шигырь сәнгатендә сәләтләрен сынау белән дә шөгыльләнгәннәр. Шундыйлар арасыннан Габдеррәхим шагыйрьнең түбәндәге иҗат үрнәген укып-тикшереп чыгарга мөмкин.

*Мөнәммикъ мәсьүл улурса, бу «Гавамилне» бетерде,*
*Хода гауне иләдер көлле кәмаль-Габдеррәхим ирур исме:*
*Остазымызны сорсаңыз, ки Яхшыкол ирур исме,*
*Әфазыйллар арасында кәсир булды аның гыйлме.*
*Сезә уасфын улам рави, фөнунлари ирур хауи,*
*Голямалар арасында кид кадри булди бик гали.*
*Атасындан сөаль улса, Җомагол дип улың карый*
*Бу икесен кыямәттә иляһем кыйлмагыл бариэ.*
*Карьясендан сөаль улса, диеп белең Иске Әлем (авыл)*
*Ходаем максудым биреп, бәни кыйл голуме уасыйль.*
*Беләм дисәң тарихыни, бәян идәм сезә ани,*
*Мең сикез йөз утуз биштә тәмам булдый шинбә йәүми.*

Бу шигырьләр «Гавамил» исемле кульязма китапның азагына теркәлгән иде. 1919 елда бу китап хәзерге Әгерҗе районы Салагыш авылының коммунист укытучы Гыйнаять абзый Адилов кулында атасы Кариб Мөхәммәтҗан углыннан мирас буларак саклана иде. Бу һәм башка шуның кебек язма китапларны караштырган чакта мин шушы шигырьләрне күчереп алдым. Сүз чыккач бу китапның кызык кына сәяхәте хакында да бер-ике сүз әйтәсем килде: Кариб мулла Адилов һәм әтием Габделҗәмил Максудов 1840–1855 елларда Тирсә мәдрәсәсендә Иске Әлем авылыннан килгән бик галим Ягъкуб бине Нигъмәтулла Мансуров дигән мөдәрристән укыганнар.

**Сүзлек:**

*Мөнәммикъ* – язучы
*Мәсьүл* – соралган
*Хода гауне* – Ходаның ярдәме
*Көлле кәмаль* – барча төгәллек, җитешлек
*Әфазыйллар* – галимнәр
*Уасф* – сыйфатлау-характерлау
*Рави* – сөйләп бирүче
*Кәсир* – күп
*Фөнүн* – фәннәр
*Хауи* – үзенә туплаучы, җыючы
*Гали* – югары, биек
*Карый* – укучы
*Бариэ* – бизүче
*Бари* – бар кылучы, яраткачы
*Карья* – авыл
*Голум* – гыйлемнәр
*Уасыйль* – олашучы, ирешүче
*Бәян идәм* – сөйләп бирәм
*Йәүми* – көне

Соңыннан К. Адилов бу мөдәрриснең кызына өйләнеп, гаилә мөнәсәбәте багланган. Шул уңай белән бу һәм башка байтак китап байлыклары Тирсә мөдәррисе Ягъкуб бине Нигъмәтулланың көтепханәсеннән Салагышка К. Адилов милкенә күчкән иде. Ягъкуб мөдәрриснең үзе дә шул ук Әлем авылында Яхшыкол мәдрәсәсендә бәлки укыгандыр. Ул ислам гыйлемнәре белән бергә математика – хисап, җәбер, һәндәсә, фәраиз (мирас бүлү кагыйдәләре) фәннәренә дә бик оста булган. Аның үзе төзегән «Хисаб вә әлҗәбер» исемле дәреслеге дә булган. Бу мөдәрриснең Мәгъдәнелкәмал исемле кызы да үзенең тирән гыйлеме белән Чулман һәм Ак Идел буйларында атаклы булган. Аның хакында Риза казый үзенең «Мәшһүр хатыннар» исемле китабында онытылмаслык мактау сүзләрен язып үтте. Бу ханымның балалары – Зәки, Миргаяз, Мирза, Мөнәвир, Мирзанур, Тәкый Алеевлар да совет мәктәпләрендә күп еллар укытып танылган көчле математиклар иде.

Бу кечкенә мәкалә татар халкының борынгы уку йортлары тарихын, онытылган галимнәрен, әдип һәм шагыйрьләрен, аларның иҗат үрнәкләрен өйрәнүчеләр өчен аз булса да материал булыр дип язылды. Бигрәк тә XVI йөздәге канлы вакыйгалар сөргене белән Бөгелмә, Актаныш, Нократ буйларына сөрелеп, шунда качып-посып булса да халык арасында ак өстендә караны танытырга – мәгърифәт орлыкларын чәчү эшен дәвам иттерергә тырышканнар. Алардан калган байтак язмалар кайберәүләрнең китап киштәләрендә, яки сарайларында тузан астында күмелеп ятуы, хәтта бөтенләй череп югалуы да мөмкин. Фазыл Туйкә унҗиденче йөз шагыйре Мәүла Колыйның «Хикмәт»ләрен шулай искәртмәс җирдә генә табып игълан иткән иде бит.


بوبی مدرسه‌سی

هیئت معلمینک سنوی تدقیقات اخلاقیه‌سنه مخصوص

فوق العاده تقدیر نامه

۸ نجی صنف شاکردانندن ... افندی ... ۱۹۱۱-۱۹۱۲ نجی

سنهٔ تدریسیه‌ده کوریلن حسن اخلاق و ... دن طولایی مکافاةً اشبو

فوق العاده تقدیر نامه اعطا اولندی.

مدیر: مفتش: ناظر: هیئت معلمینک کاتبی:

هیئت معلمین اعضالری:

**З.Максудованың Иж - Бубый авылындагы хатын-кызлар мәдрәсәсен тәмамлавы турында Мактау грамотасы**

# *Язмага карата кайбер шәрехләр*

Зәйнәп Максудованың әлеге мәкаләсе Татарстан Республикасы Милли музее фондында саклана. Аның язу машинасында күчерелгән берничә нөсхәсе (кулдан кертелгән төзәтүләр белән) һәм гарәп хәрефләрендә язылган кульъязма варианты да бар. Иске имлядагы текстта авторның берничә искәрмәсе бар. Мәсәлән, ул 1) «Таҗетдин Ялчыгол углы белән бәйләнеше юк микән?» дип сорау куя. Икенче кызыксындырган соравы: мөдәррис Яхшыкол Җомагол углы үзе кайда укыган? Нинди эшләре калган?

Чынлап та, бу мәкалә күп сораулар турында уйланырга мәҗбүр итә. Бердән, әдәбият-шигърият турында. Мәдрәсә шәкертләренең төрле

китапларны күчереп язулары, шулай итеп китап таралышы, интеллектуаль элемтәләр тәэмин ителүе мәгълүм хәл. Зәйнәп ханымның әтисе Габделҗәмил мәкаләдә искә алынган Тирсә мәдрәсәсендә белем алган елларында шулай ук моның белән шөгыльләнгән. Максудова китапханәсендә әтисе күчереп язган китаплар күп. Әмма Зәйнәп ханым китап күчерүчеләр үзләре турында язган чакта (ягъни кульязма китапның колофонында) шигырь ысулын куллануларга игътибар итәргә чакыра һәм бу шигырьләрне мәдрәсә шәкертләренең иҗат үрнәге буларак карарга тәкъдим итә.

Шәкерт дәфтәрләре, заманында археографлар һәм әдәбият белгечләре тарафыннан өйрәнелеп, фәнни кулланылышка аерым бер жанр буларак кертелгән иде. Бу эштә Зәйнәп Максудованың да өлеше зур була, чөнки, мәсәлән, нәкъ менә ул Тирсә мәдрәсәсе шәкерте Бәшир бине Габдулланың искиткеч гүзәл шигырьләрен бастыруга әзерләп куя (бу әсәрләр 1992 елда «Мәдрәсәдә китап киштәсе» җыентыгында дөнья күрде). Шәкерт дәфтәрләрендә җитди һәм шаян шигырьләр, дини рухтагы әсәрләр һәм мәхәббәт-гыйшык утында янучыларның аһ-зарлары, бәетләр, җырлар, төрле әсәрләрдән өзекләр дә очрый.

Хәлбуки колофоннардагы шигърият ул бөтенләй башка нәрсә. Аның максатлары бүтән: мондый әсәр китап күчерүче, аның бу хезмәтне башкарган урыны, мөмкин булса, аның мөгаллиме, укыган җире, күчереп язылу шартлары һ.б. турында хәбәр итү өчен иҗат ителә. Шулай итеп, мәкаләдәге шигырьдән без «Гавамил» китабын күчергән Габдеррәхимнең үз исемен дә, аның Иске Әлем мәдрәсәсендә белем алуын һәм мөдәррисе Яхшыгол (Яхшыкол) Җомагол углы икәнен беләбез.

Шушы урында уйлануларның икенче юнәлеше башлана. Хәзерге Актаныш районына кергән Иске Әлем һәм Яңа Әлем авыллары иң кимендә XVII гасыр ахырында нигезләнгән булырга тиешләр. Әлбәттә, анда мәктәп-мәдрәсәләр булган, ә Яңа Әлем авылы XIX гасырда урталарына тирә-якта даны таралган зур бер үзәккә әверелә, шул исәптән, мәдрәсәсе һәм гасыр ахырында барлыкка килгән училищесы белән дә билгеле була. Әмма Иске яки Яңа Әлемдә Яхшыгол бине Җомагол дигән мөдәрриснең булганлыгы турында хәбәрләр очраткан юк иде. Бу җәһәттән, әлбәттә, Зәйнәп Максудова күчереп язып калган шигырь тарихчылар өчен кыйммәтле чыганак булып тора.

Яхшыгол бине Җомагол (Якшигул Юмагулов) исемле мулла 1811 елгы ревизия язмасында Бурсык авылында имам буларак искә алынган. Иске Әлем мәдрәсәсендә гыйлемлеге белән шөһрәт казанган мөдәррис шул хәзрәт булса кирәк. Кызганыч, Яхшыгол хәзрәт турында әлегә бүтән мәгълүмат ачыкланмады.

Максудова язмасында искә алынган өченче шәхес – Ягъкуб бине Нигъмәтулла бине Мансур әл-Әмири (кайчак әл-Әлми дә). Ул 1823 елда хәзерге Башкортстанның Бүздәк районы Яңа Әмир авылында туган. Казан артындагы Бәрәскә мәдрәсәсендә гыйлем эстәве һәм гаять белемле, дөньяга киң карашлы, зирәк кеше булуы билгеле аның. Атаклы морза Тәфкилевләрнең утары урнашкан Килем авылында да яшәп алганы мәгълүм. Шуннан соң ул шул ук Тәфкилевләргә караган, әмма Алабуга өязендә урнашкан Тирсә авылына күчеп килә һәм мәдрәсәдә мөдәррислек итә. Тирсәдә аның шәкертләре арасында Зәйнәп Максудованың әтисе Габделҗәмил дә, Габделгалләм Буби да, шул төбәктә гыйлемле саналган тагын күп кенә кешеләр була. Габделҗәмил Максудов Ягъкуб бине Нигъмәтулла мәдрәсәсендә укыган чорда Нуреддин Габдеррәхман Җаминың «Китабе фәваидез зийаийа фи шәрхи кифая» китабын, Сәгъдинең «Гөлестан»ын, Хуҗа Мирсәед – Гыяседдин Мөхәммәд бине Хуҗа Сәеднең «Китаб Мирсәед Шәриф»ен күчереп язган.

Ризаэддин Фәхреддин «Асар» дигән хезмәтендә Ягъкуб Мансуровның кайбер фәнни хезмәтләрен дә искә ала. Үзе турында исә «галим вә фазыл, җәсүр (гайрәтле) һәм мәтин (ышанычлы), зирәк вә иҗтиһадлы иде дип тәгъриф иттеләр» дип хәбәр итә. Шулай ук Мансуровның Шиһабетдин Мәрҗани белән очрашканын, шуннан соң бөек хәзрәтнең «Бу адәм гаҗәеп сурәттә мәгълүматлы вә фәһемле икән» дип әйткәнен дә яза.

«Мәшһүр хатыннар» китабында исә Р. Фәхреддин Ягъкубның хатыны Мәгъдәнелҗамал (1906 елда вафат) турында да яза:


Ризаэддин Фәхреддин

*«Минзәлә тирәсендә шәех Фазлуллаһның кызы һәм Ягъкуб исемле олы бер мөдәрриснең хатыны. Әтисеннән уку-язуны өйрәнә. Бик матур рәсем ясау өстенә «Тарикаи-Мөхәммәдия»-не һәм «Мишкәтел-Мәсабих» нөсхәләрен язып, соңрак хаталарын төзәтә. Гарәп һәм фарсы телләрен белә. Бар гомерен җенестәшләренә укытуга һәм аларга тәрбия бирүгә багышлый».*

Бу ханым да гади нәселдән түгел. Аның әтисе – хәзерге Актаныш районының Такталачык авылында яшәгән имам һәм мөдәррис Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактавый (1871 елда вафат). Фазлулла озак еллар Эстәрлебаш авылында Нигъмәтулла шәехнең, аннан аның улы Харис шәехнең мөриде була. Соңрак үзе дә мөридләр тәрбияләү хокукына ия була, шуннан соң Такталачыкка килеп, имам булып урнаша. Риза казый язуынча, аның әтисе Фәхреддин дә шул Фазлулла ишан яраннарының берсе булган.

Ягъкуб Мансуров 1867 елда Яңа Әлем авылында мулла булырга указ ала. Балалары да шушы авылга күчеп урнаша. Ягъкуб хәзрәт Яңа Әлем мәдрәсәсен үстерүгә күп көч түгә. 1875 елда фаҗигале төстә һәлак була. Авылда аның эшен улы, Оренбург татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Лотфулла хәзрәт дәвам итә. 1882 елда аның тырышлыгы белән авылда училище – хөкүмәт мәктәбе ачыла. Лотфулланың балалары, оныклары арасында галимнәр, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклеләре, укытучылар бар. Улы Хәйреланамның кызы Гөлчирә Мансурова – Һади Такташның икенче хатыны.

Максудова мәкаләсе ахырында искә алынган Мәгъдәнелкамал һәм аның балалары турында да аңлатып үтик. Мәгъдәнелкамал хәзерге Актаныш районы Сәфәр авылында туган Габделханнан Яхшыгол улы Габделгалиевкә кияүгә чыга. Габделханнан Яңа Җияш авылында имам була. Аларның гаиләсендә чыннан да асыл уллар тәрбияләнә. Мәсәлән, Тәкыйулла Галиев (1894–1957) – Гражданнар сугышы елларында Башкорт гаскәре штабында комендант, штабс-капитан. 1929 елда Мәскәү югары техник училищены тәмамлап, инженер-энергетик булып хезмәт куя. Уфа, Чиләбе, Минск ТЭЦларын, Воронеж һәм Караганда ГРЭСларының төзелешен җитәкли. Озак еллар Свердловскида эшли. Екатеринбургта һәм Уфада аның исемендә урамнар да бар. Аның абыйлары Зәки, Миргаяз, Мирза, Мирзамөнәвир Ханнановларның укытучы булып эшләүләре һәм 1937 елда кулга алынулары билгеле. Алар барысы да диярлек Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алырга өлгерәләр. Мирзамөнәвир, мәсәлән, Казан татар укытучылар мәктәбенең имтиханын тапшыра, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, соңрак Минзәләдә һәм Алабугада педтехникум һәм партия мәктәбендә эшли. «Дарвинизм» дигән китап язуы билгеле.

Зәйнәп Максудованың бер кечкенә мәкаләсе мисалында да XIX гасырда татар мәдрәсәләре аша таралган интеллектуаль элементләрнең никадәр бай булуын күзалларга мөмкин. Хәлбуки Зәйнәп ханым кәгазь кырыена теркәп калдырган сораулар ачык кала: Иске яки Яңа Әлемдә булган мәгърифәт үзәгенең тарихы нинди? Яхшыгол Җомагол углы тагын нинди шәкертләре белән горурлана ала? Бу хакта яңа мәгълүмат табылачагына ышанып калабыз.

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



# *Тарих һәм татар эпосы:* **Чура Нарык улы**



**Чура батыр. Татар халык дастаны. – Казан: Татар китап нәшрияты. 1993. Иллюстрация. Рәссамы В. Е. Булатов**

## ЧУРА БАТЫР ТУРЫНДАГЫ ДАСТАННАР – КЫЙММӘТЛЕ ЭПИК МИРАС

Халыкның эпик мирасы аның тарихыннан, әдәби-мәдәни багланышларыннан аерылгысыз. Халык иҗатының героик эпос яисә тарихи дастан дип аталган жанры реаль вакыйгалар җирлегендә барлыкка килә һәм тарихи шәхес образын гәүдәләндерә.

Төрки халыклар, бигрәк тә татар, казах, нугай, үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз, башкорт һ.б. иҗатында шактый гына охшашлык күзгә ташлана, биредә берсенә генә нисбәтләп булмый торган, бер үк вакытта берничә төрки халыкның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итүче ядкярләр бар. Чура батыр исеме белән бәйле дастаннар да – әнә шундый әсәрләрдән. Алар XVI йөз уртасы татар ханлыкларына, аерым алганда, Казан ханлыгы тарихына турыдан-туры барып тоташалар.

Татар халык иҗатында Чура образы берничә эпик жанрда гәүдәләнгән. Чура батырга багышланган дастан, риваять, бәет, тарихи җырларның һәркайсы тарихта билгеле вакыйганы – Казан алынуны бәян итә, һәммәсе бу образны халык каһарманы буларак тасвирлау белән характерлана. Фольклорда бер үк сюжетның, теманың һәм образның төрле жанр әсәрләрендә һәм төрле формаларда очравы әллә ни еш күзәтелми. Чура батыр образы һәм аның белән бәйле вакыйгалар чагылыш тапкан эпик сюжетлар татар халкының үзендә генә дә берничә.

Татарча дастан тексты беренче мәртәбә 1862 елда ук Н.И. Березинның «Турецкая хрестоматия»сендә «Нарык Чураның хикәяте будыр» исеме белән татар телендә басылып чыккан.

### «АСЫЛЫМНЫ СОРАСАҢ...»

Дастани Чура образы Казан ханлыгында яшәгән сәясәтче, дипломат Чура би шәхесе белән шактый охшаш. Дастандагы башка образлар һәм вакыйгалар да күп яклап XVI йөздәге реаль шәхесләргә һәм хәлләргә якыная. Охшашлыклар очраклы гына булган дип карау үзен аклый алмый.

Әлбәттә, чорга кагылышлы архив документларының яндырылган булуы XVI йөзнең беренче яртысында Казан ханлыгында Чура Нарык углы шәхесенең яшәп, сәяси һәм дипломатик эшчәнлек алып барганлыгын рәсми дәлилләүдә кыенлык тудыра. Әмма әлеге затның эшчәнлеге турында Казан ханлыгы тарихын яктырткан хезмәтләрдә шактый гына мәгълүмат бар. Моннан тыш борынгы татар шәҗәрәләрен барлаучы М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган шәҗәрә үзе генә дә Чура батыр прототибын татардан эзләүнең хаклылыгын дәлилли. Галим «Чура батыр шәҗәрәсе» дип атаган документта Чура – Күкәс һәм Нарык буыннарыннан соң килүче зат. Шәҗәрәдә Чураның Нарык углы дип күрсәтелүе аның тарихи шәхескә тәгаенләнүе өчен җитәрлек нигез булса, дастандагы:

*Мән Чурамын, Чурамын,*
*Түрә түгел, карамын,*
*Асылымны сорасаң –*
*Күкес углы Тамамән, –*

дигән юллар һәм әсәрдә Чураның атасы Нарык турында җентекле тасвир исә дастан вакыйгалары белән татар шәҗәрәсенең тамырларын уртак итә. Хәлбуки дастани Чура батырны Казан ханлыгында яшәгән тарихи шәхес Чура Нарыковка бәйләүне хаксыз гамәл дип булмый, моны инкяр итә торган дәлилләр юк.

### ФОЛЬКЛОР ХӘТЕРЕ – ТАРИХТАН

Билгеле булганча, Казан ханлыгы, оешкан чорыннан алып бөтен яшәү дәвере буена Мәскәү Бөек князьлеге белән көч сынаша һәм, ниһаять, XVI йөз уртасында үзеннән көчлерәк дәүләт тарафыннан рәсми төстә яулана. Казан татарларына турыдан-туры кагылышлы бу вакыйгага реакция халык иҗатының эпик жанрларында, иң беренче чиратта, дастаннарда яңгыраган. Героик китаби дастаннардан «Чура батыр» – халыкта милли фаҗига итеп кабул ителгән вакыйгаларның кайтавазы.

Тарихи шәхес буларак Чура Нарык углының яшәү һәм эшчәнлек дәвере чама белән XVI гасыр башы – XVI гасыр урталарына, ә төгәлрәк итеп әйткәндә, 1500–1546 елларга туры килә.

Чыганаклар күрсәткәнчә, XVI йөзнең 20 нче елларында ул Казанда хөкүмәт әгъзаларының берсе булган, шушы чордан башлап, үзенең сәяси эшчәнлеген башкарган. Казан ханлыгында Сафагәрәй (1524–1532), Җангали (1532–1533), янә Сафагәрәй (1533–1546), Шаһгали (1546 елда 1 ай хакимлек итә) ханнар идарә иткән дәвердә Чура Нарыков – ил тормышында, дәүләт эшендә актив катнашучыларның берсе. Бу елларның Казан ханлыгы өчен гаять катлаулы һәм каршылыклы булганлыгы мәгълүм.

Чура – XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән Казан аксөяге булган. Казан ханлыгында бәк (би, әмир) дип эре җир биләмәләре булган аерым кешеләрне атап йөрткәннәр. Эре феодаллар, нигездә, аксөяк нәселдән килгәннәр. Ханлыкның иҗтимагый төзелеше закончалыгыннан чыгып фикер йөрткәндә, Чура бәкнең дә атасыннан мирас булып күчкән эре җир биләмәсе булган, ә коралланган үз гаскәре хан фәрманы карамагында торган. «Казан тарихы»ның билгесез авторы искәрткәнчә, чыннан да, Чураның «500 йомышлы (хәрби хезмәт үтәүче. – *Л.М.*) коралланган колы, 1000 сугышчы-яугире, үзенә ияргән князьләре» булган.

Чура бәк 1526 елдан илнең эчке һәм тышкы сәясәтендә, аерым алганда, үз дәүләтенең Кырым ханлыгы һәм Мәскәү белән мөнәсәбәтләрен урнаштыруда әһәмиятле урын биләгән. Казан ханлыгының үз эчендә барган иң киеренке көннәре дә нәкъ менә 1530 – 1546 елларга туры килә. Моны ханнарның еш алыштырылуы, ике төркем арасында барган ызгыш-талаш, урыс дәүләте белән әледән-әле булып торган бәрелешләр раслый.

1546 елда, Казанда кулга алулар башлангач, Сафагәрәй хан оппозицион төркем вәкилләрен җәзалый. Барыннан да элек Чура бәк һәм аңа якын түрәләр кулга алына. Тарихи әдәбиятта әлегә кадәр Чура Нарыковның 1546 елның көзендә Сафагәрәй тарафыннан үтерелүе турында мәгълүмат таралган.

## ЭПОСМЫ, ТАРИХИ ХРОНИКАМЫ?

Дастани Чура батыр татар версиясендә дошманнары белән каты көрәшә, дошман гаскәрен рәхимсез кыра. Ахырда ул дошман ягыннан китерелгән хатыннан туган үз улы белән сугыша, җиңүгә ирешә алмый, ярсыган атына атланган килеш Иделгә егылып төшеп, суга батып үлә. Менә шуннан соң дастан тәмам булырга тиеш кебек, әмма эпик вакыйгалар дәвам итә: «Соңра урыс гаскәре галиб булып (җиңүче булып), Казан шәһрене алды. Урыс падишаһына табигъ булдылар (буйсындылар). Бу Казан шәһрен алгандан бер ел соңра Хаҗитархан (Әстерхан) шәһрен янә алды. Чура батыр хикәяте тәмам булды» [Нарык Чураның хикәяте будыр // Турецкая хрестоматия, 1862. 59 б.]. Дастан ахырында китерелгән әлеге юллар Чура батырга багышланган татар эпосына өр-яңа биеклектән карарга мәҗбүр итә. Дастан батыр гамәлләрен сурәтләү белән генә чикләнми, ә Алтын Урда варислары булган Казан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Нугай ханлыгы вакыйгаларына турыдан-туры кагыла! Әсәр XVI йөз уртасы тарихи вакыйгаларының эпик картинасын тудыра. Бу дастанны Алтын Урда чоры эпик истәлеге «Идегәй»нең дәвамы дип атарга мөмкин. «Идегәй» Алтын Урда таркалу вакыйгаларын сурәтләсә, Чура батырга багышланган дастанда Алтын Урда таркалып, татар ханлыклары барлыкка килеп, билгеле бер чорда аларның үз көчен югалтуы тасвирлана.

Шулай итеп, татар, нугай, казах, кырымтатар, башкорт, кыргыз халык эпик иҗатында аның популярлыгы чын мәгънәсендә тарихи чынбарлык белән бәйләнгән. Чура Нарыков гомере буе көрәшеп яшәгән, үзен шактый көчле сәяси һәм җәмәгать эшлеклесе итеп танытуга ирешкән, халык ышанычын яулый белгән. Чураның эпик биография югарылыгына күтәрелүендә аның нәкъ менә шушы сыйфатлары әһәмиятле роль уйнаган булса кирәк. Әлбәттә, каһарман образының дастани үрнәгеннән тарихи Чура нык кына аерыла. Аның эшчәнлегенә объектив бәя биргәндә, сәясәттә кайбер ялгышлар җибәрүен дә күрми мөмкин түгел. Бүгенге көн югарылыгыннан карагенда, көнбатыштан басып керүгә каршы уртак көрәштә Казан-Нугай, Казан-Кырым, Казан-Себер, ниһаять, Татар-төрек берләшмәләре төзү отышлырак булыр иде. Ә Казан дипломатиясе, шул исәптән Чура Нарыков та бу максатта ифрат йомшаклык күрсәтә. Шул ук вакытта Чура бәк яшәгән дәвер көнчыгышның берләшүенә комачаулау өчен Мәскәүнең актив төстә нәтиҗәле



Р. Г. Шәмсетдинов. «Чура батыр» эпосына иллюстрация. 2000 ел. Авторның шәхси милке

эш алып бару чорына туры килә. Күренекле дәүләт эшлеклеләре Булат һәм Нурали Ширин, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Чура Нарыков, Кучак һ.б. сәяси һәм иҗтимагый көчләрнең бердәмлеген булдыра алмыйлар, хан идарәсе белән хөкүмәт бердәм эшләми, халыкны бер максатка туплый алмый. Бу һәм башка сәбәпләр ханлыкларның һәлакәтенә китерә. Бер караганда, Чура батырның дастаннардагы чагылышы образлы рәвештә Чура бәкнең каршылыклы сәясәтен күрсәтә кебек. Дастани Чура да җиңү максаты белән дошманнарына каршы көрәшә, әмма язмышын фаҗигале төгәлли. Эпик Чура – идеальләштырылган образ, ә чынбарлыктагы Чура Нарыков – дәүләтнең бөтенлеген саклап калу өчен иң җаваплы чорда яшәп эшчәнлек алып барган кеше, илдә бердәмлек булмаган болгавыр дәвернең бер вәкиле генә.

Гомерен Казан хөкүмәте эшчәнлегенә багышлаган Чура бәк татар, кырымтатар, казах, нугай халык дастаннарына ил азатлыгы өчен көрәшкән батыр шәхес буларак килеп кергән. Халык хыялы аның эпик биографиясен 1552 елгы мәгълүм көрәшкә үк китереп җиткергән, алай гына да түгел, Казан ханлыгының һ.б. татар ханлыкларының яулап алынуын шушы көрәшкә китереп бәйләгән.

**Татар халык иҗатында Чура образы берничә эпик жанрда гәүдәләнгән. Чура батырга багышланган дастан, риваять, бәет, тарихи җырларның һәркайсы тарихта билгеле вакыйганы – Казан алынуны бәян итә, һәммәсе бу образны халык каһарманы буларак тасвирлау белән характерлана.**

2026 ЕЛ ТАТАРСТАНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

# Кадерле ядкяр

**Бөек шагыйрьнең Казан шәһәрендәге Г. Тукай әдәби музеенда саклanучы мемориаль әйберләре һәм алар белән бәйле хатирәләрне яңартып алыйк.**

## ТҮБӘТӘЙ – БАШ КИЕМЕ

**Россия, Казан губернасы, Казан. XX гасыр башы. Кара төстәге бәрхеттән кулдан сырып эшләнгән. Диаметры – 15,5 см, биеклеге – 6 см. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган.**

Г. Тукайның замандашлары истәлекләренә караганда, 1908 елда фотосурәткә ул шушы түбәтәйдән төшкән. Баш киеме шагыйрьгә аның бөтен китапларын диярлек үзенең «Үрнәк» матбагасында бастыручы нашир Гыйльметдин Шәрәф тарафыннан бүләк ителгән. 1908 елда нәшер итү өчен яңа шигырьләр җыентыгы әзерләнә. Нашир китапны авторның фотосурәте белән бастырырга тели. Ул Тукай белән С. И. Иванов фотосалонына бара. Г. Шәрәф, шагыйрьнең озын чәчләреннән кыенсынуын күреп, кесәсеннән пөхтә итеп төрелгән түбәтәйне алып, аның башына кидергән.



## ТАРТМАЧЫК

**Россия. XX гасыр башы. Керәч (фаянс) тартмачыкның диаметры – 14 см, биеклеге – 8 см. Музейга аны Г. Тукайның әтисе ягыннан апасы Газизә Зәбиреваның Казан шәһәрендә яшәүче улы Хөсәен Зәбирев тапшырган.**

Истәлекләр буенча, Г. Тукай бу тартмачыкны Җаек шәһәрендә үзенең беренче гонорарына сатып алган һәм әтисе ягыннан апасы Газизәгә бүләк иткән булган.





**Х. Якупов.**
**«Г. Тукай һәм аның апасы Газизә Уральск шәһәрендә».**
**1971, ТР Милли музее**

## ҖИҢ КАПТЫРМАЛАРЫ

**Җиң каптырмаларында аны ясаган останың инициаллары күрсәтелгән: «D.G.M.», «OCTER. PAT» Германия, XX гасыр башы. Көмеш. 2x1,3 см. Казан шәһәрендә яшәүче А. А. Низаметдинов тапшырган.**

Җиң каптырмаларын рәссам А. А. Низаметдиновка 1950 елларда «Аң» журналының җаваплы сәркатибе Зәйнәп Хәсәни (мөхәррире – ире Әхмәтгәрәй Хәсәни була) тапшыра. 1911–1912 елларда Ә. Хәсәни Австрия һәм Германиядә була. Җиң каптырмаларын шунда сатып алуы ихтимал, ә соңрак дусты һәм хезмәттәше Г. Тукайга бүләк итә.





## КАРАНДАШ САВЫТЫ

*Петербургка нигез салынуның 200 еллыгына багышлап эшләнелгән. Петербург гербының, Пётр I һәм аның ике йортының кабарынкы рәсемнәре белән бизәлгән. «Санкт-Петербург шәһәренең 200 еллык юбилее истәлеге итеп. 16 май, 1908 ел» дигән язу бар.*
**Россия, Санкт-Петербург. XX гасыр башы. Аккургаш. Нигезенең диаметры – 5 см, өске ягының диаметры – 6,3 см, биеклеге – 10 см. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган.**

Казан шәһәрендә яшәгән композитор Мансур Мозаффаров СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыра. Аның сүзләре буенча, карандаш савытын Г. Тукай 1912 елда Санкт-Петербургка сәфәре вакытында сатып ала.



## КАРА САВЫТЫ

Рәвеше үзенчәлекле: аскуймада ау эте утыра, янәшәдә аучының зур эшләпә белән капланган киеме һәм мылтыгы. Савытның кара сала торган өлеше дә шушы эшләпә астында.

**Россия, XIX ахыры – XX гасыр башы.**
**Бакыр. 21х15х9 см.**
**СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган.**

Казан шәһәрендә яшәгән композитор Мансур Мозаффаров СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыра. Кара савытын шагыйрьгә Санкт-Петербургның татар мәктәбе укучылары 1912 елгы сәяхәте вакытында бүләк итә. Бу бүләк Тукайга бик кадерле була. 1945 елга кадәр кара савыты М.Мозаффаровның әнисе гаиләсендә, Г. Тукай белән якыннан таныш булган Маһруй Мозаффариядә саклана. Аның кияве Әхмәт Урманчиев «Ялт-Йолт» сатирик журналының мөхәррире, ә шагыйрь анда җаваплы сәркатип булып эшли. Г. Тукай үлгәннән соң, кара савыты Ә. Урманчиевта саклана. Әнисенең васыятен үтәп, М. Мозаффаров аны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыра.

## ЮЛ КӘРЗИНЕ

**Камыш. 21х53х34 см.**
**СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган.**

Кәрзинне СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына Казан шәһәрендә яшәгән композитор Мансур Мозаффаров тапшыра. Аның әйтүенчә, юл кәрзине шагыйрьнең сәяхәтләре вакытында юлдашы була.



# Татар аты

**(ДӨНЬЯ «АТ ЕЛЫ»НА КЕРДЕ. БУ ЯЗМА ШУЛ УҢАЙДАН)**

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
*язучы, әдәбият белгече*



Төрки халыкларның традицион уен-йолаларында элек-электән атлар төп рольне башкарган. Кыргызларда «Кыз куумай» дигән икенче ат өстендәге кызны куып тоту уены бара; кызны куып тотып, үбеп алган егет кире атында чабып кайта, аны кыз куып килә. Әгәр ул егетне куып җитеп, камчы белән ора алса, җиңгән була, ора алмаса, егет җиңә... Бу йола үзбәкләрдә «Кыз кувмак» дип йөртелә, ул Яңгыр бәйрәме белән турыдан - туры бәйләнгән, төрекмәннәрдә дә шундый ук йола барлыгы билгеле; казахларда ул «Кыз куу» дип атала... Башкортстан, Оренбург далаларында яшәүче татарларда, башкортларда шуңа охшаган уен Сабан туе башланыр алдыннан башкарылган.

Андый йола уены Енисей татарларында, хакасларда булган. Ул «Кызны тот» («Хысты тут») дип аталган. Бу очракта кыз атлы егетне үзен тотып үбә алмаган очракта гына камчылый... Бу йола уены вакытында кыз ике ат буе алдарак тора, әмма алар бер үк вакытта кузгалып, чабып китәләр. Кайчакта алар янында өченче атлы да пәйда була. Ул – кызның җиңгәсе. Куып килүче егетне кызга якын җибәрмәскә тырыша ул... Җиңгәләргә егеткә дә, аның атына да камчы белән сугу тыелган.

Кайчандыр Сабантуй чараларында атлылар, җирдә яткан сарык бәрәне өчен тарткалашып, үзләренең елгырлыкларын, көчләрен сынаганнар. Бу йола уены барлык төрки халыкларда да диярлек булган.

Татарларда, кайбер башка төрки халыкларында да, атлар чабышы, нигездә, Сабантуй бәйрәме белән бәйле. Ул «Бәйге» дип атала. Урта Азия төркиләрендә «Байга», үзбәкләрдә «Пойга» дип тә әйтәләр. Элек-электән бәйгенең төгәл кагыйдә-кануннары булган. Бу катгый кануннар бер генә максаттан кулланылганнар: атларны ерак походларга әзерләргә кирәк булган. Бу кагыйдәләр буенча, атлар ерак араларга чабарга тиеш (10-15 чакрымга), алар билгеле бер урыннан (бу урынга әләмнәр кадап куйганнар) урап, әйләнеп кайтырга тиеш булган. Старт белән финиш бер урында булган. Кыска араларга оештырылган бәйгеләр исә казахларда, дала татарларында киң таралган. Алар аны «Кунан бәйгесе» («Кунан байга») дип атаганнар. Кулга ияләшеп кенә килгән өч яшьлек атлар «кунан» дип йөртелгән.

Татарның милли Сабан туенда ат чабышлары (бәйгеләр) – бәйрәм программасының төп чарасы. Сабантуйдагы бәйгеләр белән бәйле бик күп ышанулар, им-том, әфсен догалары, арбаулар сакланып калган. Бу хакта аерым тема алып сөйләшергә мөмкин булыр иде. Ләкин бер изге йола гамәле татарда гына очрый. Бу хакта әйтми китү мөмкин түгел. Татарлар чабышта иң соңгы килгән атка затлы бүләк биргәннәр. Кызыл башлы тастымал (сөлге) булган ул. Аны атның йөгән каешына авылның иң хөрмәтле ак әбиләре барып бәйләгән. Бәйли-бәйли, атларның колагына әфсен пышылдаганнар:

*Ходай хакына, рухлар хакына*
*Карама алга, кара ягыңа.*
*Кызыл тастымал тиреңне сөртсен,*
*Алда сине дә җиңүләр көтсен!..*

Дәвамы. Башы алдагы санда.




**Илдар Зарипов. «Өтәчле кыз». Киндер, майлы буяу**

## АТАМАЛАРДАГЫ «АТ»ЛАР

Татар телендәге образлы сөйләмгә игътибар итик, кая гына баксак та ат лексикасына тап булабыз: ат-казанган, кушам-ат, ат-ама, ат-кару (ат-карып (башкарып) чыгу), ат-лыгу (атлыгып (ашкынып) тору) һ.б. «Ат»ны «исем» белән тәңгәлләштереп әйтү татарда аеруча мөһим мәгънәгә ия. Ә менә «егәрле-җегәрле» («йигәрле-җигәрле») сүзе турыдан-туры «җигү» сүзенә килеп бәйләнә. «Җигәрле» («җегәрле»), димәк ки, «җигәрлек», «җигүле» – көчле, чыдам, максатлы! «Атлау» – «атлату», «атлам» сүзләрендә дә «ат» бар бит!

«Ат» сүзенең килеп чыгышын ике яклап аңлаталар: борынгы төркиләрдә атларга карата «ахта» сүзе кулланганнар. Монгол телендә атларны белдерә торган «агыт» сүзе бар. Татарга бу атаманың ике яклап та килүе ихтимал. Гомумән, татарлар атлар белән бергә туган кебек тәэсир кала. Әлбәттә, «Ат» атамасы белән янәшә аның башка ишләре, синонимнары да кулланылган. Мәсәлән, борынгы төркиләрдә «ат» мәгънәсендә «йунд» атамасы да кулланылган, кулъязма мираста шулай ук «бахбай», «имнек», «елкы» («йылкы, җылкы») сүзләре дә теркәлеп калган.

Чыннан да, галимнәр атны беренче башлап төркиләр кулга ияләштергән дигән фикердә торалар. Борынгы чыганакларга караганда, төрки бабалар беренче атларга моннан дүрт-биш мең еллар элек (алты-җиде мең ел белән билгеләүчеләр дә бар) Евразия далаларында атланганнар. Атны кулга ияләштерү кешелек тормышында зур ачышларга сәбәпче булган. Ат белән йөк ташу, юл йөрү кешеләргә яңа яшәү мөмкинлекләре биргән. Металл кулланып, ат дирбияләре, тәгәрмәч, арба, чана кебек җиһаз-җайланмалар уйлап табылган. Йөгән, авызлык, өзәңге, ияр һ.б. – һәрберсе зур ачыш буларак кабул ителгән.

АТЛАР нәселенең җиде төре билгеле: кыргый ат, кианг(ң), колан, ишәк, тау зебрасы, чүл зебрасы, тигезлек зебрасы.

Җир йөзендә ике йөзгә якын ат токымы бар дип санала. Аларның һәрберсенең халык тарафыннан кушылган исем-аты бар. Мәсәлән, адымлы (атлап йөри торган) атлар, юртак атлар, атланып йөри торган атлар, гарәп чиста канлы аты, чиста канлы атланып йөри торган ат, инглиз-гарәп аты, ярым чиста канлы ат һ.б.

Ләкин атлар иң элек кыргый атларга һәм йорт атларына бүленәләр әле. Әлбәттә инде, кыргый атлар беренче булып барлыкка килгән, йорт атлары кыргый атларны кулга ияләштерү нәтиҗәсендә үрчеп, яңа токымнар пәйда булган. Өстәвенә йорт атлары – Пржевальский атыннан тыш, кыргый атларның сакланып калган бердәнбер төре булып тора. Аларның иң данлыклы токымнары: ахалтәкә аргамагы, башкорт аты, брабансон (Бельгия), монгол аты, татар аты... Атлар тарихында Карабаир аты үзенә бер урын тота. Үзбәкстан һәм Таҗикстанда үрчетелә торган эссегә чыдам, ияргә, йөккә һәм җигүгә яхшы яраклашкан ат токымын шулай атап йөрткәннәр. Карабаир юрга дигән исеме дә бар бу токымның.

Соңгы берничә дистә елда ТАТАР АТЫн торгызу, чистарту, кайтару, гамәлгә кую омтылышлары ясала. Тәбәнәгрәк зифа буйлы, йөнтәсрәк тәнле, юлга чыдам, эссегә һәм салкынга түзем татар аты Кама буе районнарында шактый популярлашып килә.

Йорт атлары, Антарктидадан тыш, барлык континентларда да таралган. Атларны беренче тапкыр төрки халыклар кулга ияләштергән, аннары башкалар үз йортларына алган, дип уйланыла. Шуңа күрә, мәсәлән, урыс һәм башка телләрдә ат лексикасында төрки-татар сүзләре күп: лошадь, мерин, табун, каурый, чалый, буланый, скакун һ.б.

Йорт атларының халыкара гыйльми исеме – Ekuus caballus. Бүгенге фән аларны 4 төргә бүлеп карый:

1. Йөк атлары – эре сөякле, зур башлы һәм көчле мускуллы хайваннар. Аларны авыр йөк ташу өчен файдаланалар. Йөк атлары арасында иң билгеле токымнар – Бельгиянең «брабансон» аты, Владимир авыр йөк аты, «шир» (Англия), «першерон» (Франция) атлары һ.б.

2. Җигүле атлар, гадәттә, көчле, әмма уртача гәүдәле булалар. Төялгән йөкләрне яки пассажирларны ташу өчен кулланылалар.

3. Юртаклар – җиңелчә җигемне зур тизлек белән тартып алып бара торган атлар. Иң танылганнары – Орлов рысагы, Урыс рысагы.

4. Аргамаклар (аргымаклар) – бу токымнар атланып йөрер өчен махсус чыгарылганнар.

Сыбай (атланып) йөрер өчен иң шәп атлар – гарәп, ахалтәкә аргамаклары, шулай ук терек токымнары.

Атларның функциональ төрләренә караган, халык телендә йөргән атамалары да бар: юл (сәфәр) аты, йөк аты, басу (буразна) аты, сабан аты, чәчү аты, кыр аты, болын аты, урман аты, сал аты, чабыш аты, ярыш аты, туй аты, сугыш (яу) аты, хәрби ат, фронт аты, каравыл аты, пожар аты, шахта аты, ям аты (почта аты), чыгыр аты (су тегермәне белән бәйле) һ.б.

Пар ат, өчле, мичәү аты дигән атамалар атны ни рәвешле җигү белән бәйләнгән: парлап, өчләп, янәшә.

Өер аты, табун аты дигән төшенчәләрдә атларның көтүчелек белән бәйле атамалары чагылыш тапкан.

Шулай ук борынгы халык йолаларыннан калган сугым аты, корбан аты дигән төшенчәләр дә билгеле. Борынгылыкта тәннәрендә бер бөртек тә тап булмаган ак һәм күк төстәге корбан атларын изге ат, йола аты, тәңре аты дип тә йөрткәннәр.

## МИФИК АТЛАР

Пегас (канатлы ат) – акбүз төстәге ала атларга карата кулланыла. Ян-як сыртларында эре һәм озынча караңгы тимгел-тамгалар читтән сыртларына җыеп куелган канатларны хәтерләтәләр. Бу «канатлы» мифик персонажлар нигездә иҗат, шигърият символы буларак телгә кергән. «Канат» сүзендәге «ат» компоненты да игътибарга лаек, «кан» сүзенең борынгылыкта изгелекне белдерүен искә төшерсәк (ягъни, «изге ат»), хәтердә кошларның канатлары ялгау белән бәйле миф-легендалар яңара...

Пегас атамасы «пегий» сүзенә барып тоташа дип саныйлар. Бу очракта ал, кызгылт төстәге атлар (ал төс – мифологиядә тылсым, сихер төсе) күз уңында тотыла икән, кантлары канап ялгаган атлар тарихы аңлашыла булса кирәк.

Борак (бурак, порак, пырак) – мөселман мифологиясе буенча, адәми затларны күккә ашыра торган канатлы ат. «Идегәй» дастаныннан мисал:

*Борак сынлы ат менеп,*
*Билек сөргән морзамын...*

Борак – Җәбраил фәрештә тарафыннан Рәсүлуллага (Мөхәммәд) Мигъраҗ, аның күз ачып йомганчы (яшен кебек) күккә ашуы һәм кире әйләнеп кайтуы өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан махсус бирелгән могҗизалы хайван. Аны аттан түбән, ишәктән калку итеп сурәтлиләр. Бу мифик персонажның төп асылын исеме үк әйтеп тора: гарәпчә «бәркъ» сүзе «яшен» дигәнне белдерә.

Дөлдөл – мифик ат. Габделҗәббар Кандалыйдан юллар:

*Ки сының дөлдөлә биңзәр,*
*Йөрисең былбыла биңзәр...*
(«Ярattым, ярың булмадым».)

Дөлдөл – ислам мифологиясендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең канатлы ак аты; керпе дип аңлатыла, чөнки ул юыртып йөри. Пәйгамбәргә Искәндәрия падишаһы тарафыннан бүләк ителгән булган. Мөхәммәд пәйгамбәрдән ул Гали сәхабәгә мирас булып калган.

Бу мифик образ иң элек Ә. Ясәви хикмәтләрендә чагылыш таба. Шагыйрьнең «Илле җиденче хикмәте» тулысынча диярлек Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган, анда Дөлдөлгә дә урын күп бирелгән. Суфи шагыйрьләр мирасында еш очраган бу персонаж Дөнья Аты итеп түгел, бәлки, Җиргә Изи (Ходай) тарафыннан иңдерелгән ат буларак тасвирлана. Аны кем тели, шул кулга ияләштерә, файдалана алмый. Ул үзе дә, бер илаһи зат буларак, үзе кебек яки шуңа якын изге затларга гына хезмәт күрсәтә.

Тулпар (толпар) – борынгылыкта гаскәри атлар булып йөргән тулпар атларның легендар төрләре дә бар. Әкият-легендаларда бу атлар шулай ук канатлы атлар буларак тасвирланалар. Төрки мифологиягә тулпар (толпар) судан яки зур дәрья-океаннар башланган җирдән чыккан тылсымлы, канатлы ат буларак кереп калган.

Безгә таныш «Идегәй» дастанында Туктамыш хан Кобогылга тулпар ат токымыннан булган Тимгел чуар атны сайлап бирә: «Токымы тулпар ялгаган Тимгел чуар ат бирим...»

Халык җырында: «Көмеш тояк тулпар атым!..»

Әсб (әсеб) – канатлы ат, тулпар (толпар). Мөхәммәтсәлим Өметбаевта:

*Ул атымны яд итсәм, белең васфын,*
*Кыйссаларда күрдегезме Хатим әсбен?*

Бөкрәч ат – рус халык әкиятендәге Конёк-Горбунокның бер ише. Бөкре булса да, өлгер, җитез, зирәк ат. Тоягында исә ялында, кайчакта маңгаендагы кечкенә мөгезендә тылсым бар, дип тә әйтәләр. Шундыйрак бөкрәч-кәрлә атлар татарларның халык ышануларында, миф-риватьләрендә сирәк кенә очрый.

Чүбин аяк – «Идегәй»дә Субра ерау хакында: «Чүбин аяк ат менгән...» – диелә. Чүбин аяк – «агач аяк» дигән сүз. Магик мәгънәсендә «җеназасы күтәрелер көн җиткән» дигәнне аңлата.

Агат (ак ат, күк ат) – төркиләрдә элек-электән изге атлардан саналган, «Тәңре аты» образ тезмәсендә дастаннарга кергән. Бу альбинос атларны эшкә куймаганнар, күбрәк аранда тотканнар, бәйрәм-йолаларда, төрлечә бизәп, мәйданга алып чыкканнар, корбан малы буларак та еш кулланганнар.

Батыр аты – күп кенә Шәрык халыкларының мифология, фольклор һәм язма әдәбиятында популяр булган персонаж; шулай ук язмыш символы буларак та гәүдәләнә. Ул тугрылыклы ярдәмче, эпик геройның яклаучысы, аңа уңыш алып килә, баһадирны башка дөньяга күчерә ала. Батыр аты атларны ияләштергән вакыттан алып, күп кенә халыкларның тотемик хайваны буларак күзалланган.

Батыр аты образының килеп чыгышы күк-һава (Алтай эпосы «Алтын Бизе»), су асты (татар-башкорт риваятьләре «Акбүзат», «Урал батыр») һәм җир асты («Йиртөшлек») патшалыклары белән бәйле. Батыр аты баһадирның үткәнен, бүгенге көнен һәм киләчәген белә, аңа янаган куркыныч хәлләр хакында искәртә, үлемнән коткара яки үлгәннән соң терелтә. Ләкин баһадир аны иң элек табарга һәм үзенә буйсындырырга тиеш. Батыр атын җир астыннан табу, күбесенчә, ата-бабаларга табыну белән бәйле. Аерым очракларда батыр аты үлгән атаның үз каберен саклаучы иң кечкенә улына бүләге булып тора. Төрки-татар героик эпосында баһадирның һәм аның атының бер вакытта туу мотивы (урта гасырлардан килә) киң таралган. Алар бер-берсеннән башка яши алмаганга күрә, бербөтен булып китәләр кебек. Батыр атын шул рәвешле тасвирлау төрле арттыруларга корылган. Бу уңайдан, аеруча илаһи чыгышы белән билгеле һәм асыл сыйфатларга ия булган ак ат макталган.

Мифологиядә «җен атлары» дигән атама бар. Бу очракта һич шикләнми әйтергә мөмкин: бу ышанулар Коръән тәгълиматына да туры килә: җеннәр дә, кешеләр кебек, үз тормышлары белән яшиләр, ләкин кеше күзенә күренмиләр. Әмма җеннәрнең үзләренә параллель дөньяда яшәүче кешеләр тормышын күрү сәләте бирелгән. Менә шул: җеннәр кешеләрдән читләшебрәк яшәргә тырышсалар да, кеше тормышында зур роль уйнаган бер җан иясеннән – атлардан һич качмыйлар, ди. Атлар – җен халкының иң сөйгән хайваны, шуңа да ул иң матур, чиста, камил, чыдам хайван буларак яратылган да. Кыскасы, атлар элек-электән изгеләр рәтендә булган.

Җеннәр дә, кешеләр кебек, атларга атланып йөрергә яраталар, имеш. Ләкин кеше күзенә күренмиләр, ди, Шуңа күрә ялан кырдан манма тиргә батып чабып кайткан атларга элеккеләр һич аптырамаганнар, «җеннәр шаярган» дию белән чикләнгәннәр. Монда атларга атланып йөрергә яратучы Шүрәле хакындагы риваятьләрне дә искә төшерергә туры килә.

Иң кызыгы, илаһи мифологиягә игътибар итсәк, шул да ачыклана: җеннәрне – кешеләр белән янәшә, аларга күренмичә яшәүче рухи затларны күрү сәләте нәкъ менә атларга бирелгән. Шуңа күрә дә борынгылар атларга илаһи бер җан иясенә караган кебек караганнар. Тагын бер искитәрлек ышану: әгәр җеннәр кеше күзенә күренергә теләсәләр, алар бәндәләргә атлар булып күренергә тырышалар икән...

Элгәрерәк мәетне зиратка алып барган кешеләр төркеменә ат (атлар) ияртеп җибәрү гадәте булган. Атларга әйбәт җеннәр генә иярә алган, димәк, атлар озата барган мәрасим (җеназа) төркеменә җен-шайтаннар якын да килә алмаган... Шулай итеп, атлар мәрхүмне һәм аның якыннарын яман рухлардан, кара шаукымнан саклап бара торган булган.

# МОҢ ИЛЧЕСЕНЕҢ *үз вазифасы*

Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ,
*Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, профессор*




*Ишеттем мин кичә: берәү җырлый*
*Чын безнеңчә матур, милли көй...*
*Г. Тукай*

## БУ ҖЫРНЫ ТӘКЪДИМ ИТЕП БУЛАМЫ?

Дөнья буйлап сибелеп яшәүче татар халкының хәтер сандыгында сакланып килгән рухи мирасы – гореф-гадәтләре, җыр-биюләре буыннан-буынга күчеп яшәргә тиеш. Тамырларыбыздан аерылмыйк дисәк, без иң беренче нәүбәттә фольклор материалларын өйрәнеп, аз-маз камилләштереп җырларыбызны, биюләребезне тамашачыбызга тәкъдим итәргә тиешбез.Бу – үтә дә җаваплы һәм кирәкле гамәл. Кая гына барып чыксак та, күрәбез: җырсыз-моңсыз халык юк. Әмма бүген Арча, Саба, Балтач якларына чыгып гына фольклор материалы табу икеле, чөнки алар – моңа кадәр дә шактый өйрәнелгән төбәкләр. Шуңа да карамастан фольклорыбыз бик бай һәм бик төрле. Әйтик, Себердә гомер итүче милләттәшләребезнеке керәшен татарларыныкына охшамаган. Свердлов, Курган, Самара якларында гомер итүче мишәрләребезнең фольклоры үзенә бер. Аларда күргән «Ярмәк» көен мин үзебезнең фольклор ансамблендә көен ничек бар, шулай калдырып, хәрәкәтләрен файдаланып, өр-яңа җырлы-биюле инструменталь әсәр буларак тамашачыга тәкъдим иттем. Программабызны бизәп торучы, иң үтемле әсәрләрнең берсе булып тора ул хәзерге вакытта. Кытайда яшәп ятучы татарларның «Әти-әни», «Лимонад» кебек йөрәккә үтеп керә торган җырларына мөкиббән китеп, аларын да эшкәртеп, фольклор музыкасы дәүләт ансамбле репертуарына кертеп җибәрдем. Эшкәртүен эшкәртәбез, әмма музыкаль фольклорның асылын саклап калу мөһим. Юкса Казан тирәсендәге фольклор төркемнәрнең кайберләре, заманга яраклашабыз дип, кыйблаларын югалта бармыймы икән әле, дим. Бу – безне борчый торган нәрсә, әлбәттә. Фольклорны тоярга кирәк, ул – үзе бер дөнья, андагы җырлау халәте дә башкачарак. Шуңа күрә дә мин кайсыдыр авыл апасы, яки агасының җырлавын нәкъ менә шул халәте өчен ныграк та яратам әле. Репертуарга җыр сайлаганда, һәрвакыт үз алдыма шундый сорау-таләп куям: «Киң катлам тамашачыга бу җырны тәкъдим итеп буламы? Ул аны ничек кабул итәр?» Фольклор дөньясына чумганчы һәр коллектив үзенә бирергә тиешле сорау бу. Чөнки кулга килеп кергән һәрбер җырны да сәхнәгә чыгарып булмый. Чыксын дисәң сәнгати яктан үстерергә, камилләштерергә кирәк. Фольклорчылар тарафыннан архивларга алып кайтып тапшырган җырларның бик сирәге генә сәхнәгә менә. Аларны сайлап алганда эчке тоемлау да кирәк.





**Дөнья буйлап сибелеп яшәүче татар халкының хәтер сандыгында сакланып килгән рухи мирасы – гореф-гадәтләре, җыр-биюләре буыннан-буынга күчеп яшәргә тиеш. Тамырларыбыздан аерылмыйк дисәк, без иң беренче нәүбәттә фольклор материалларын өйрәнеп, аз-маз камилләштереп җырларыбызны, биюләребезне тамашачыбызга тәкъдим итәргә тиешбез.**

## ГӨСЛӘ, КЫЛКУБЫЗ ҺӘМ ДАВЫЛ

Соңгы елларда гөсләләр , сазлар, думбралар белән җырлау кебек тагын бер юнәлеш барлыкка килде. Әйтергә кирәк, бу җиңел юл түгел. Төрки музыка уен коралларын яңадан торгызу проекты өчен «Татнефть» хәйрия фонды рәисе, «Татнефть» АҖ генераль директоры, коллектив җитәкчесе Н.Ә. Маганов һәм иҗат төркеме әгъзалары П.Д. Корчагин, Э.З. Чавлинов, С.Ю. Вертелецкий быел хәтта Тукай премиясенә лаек булдылар.

Гөсләләр элек-электән безнең Балтач якларында бар иде. Гөслә чиртеп җырлауның тәэсире күңелемә малай чакта ук кереп калган. Бу өлкәдә бик актив, җиң сызганып эшләп килүче мөхтәрәм шәхесләребезнең берсе Геннадий Макаровны әйтер идем. Ул – гөслә, кылкубыз, саз, думбра кебек уен коралларын торгызган кеше. Икенче яктан, думбра, гөслә белән генә дә киң тамашачының күңелен яулап булмый. Монда аны ниндидер сюжетларга таянып, ниндидер тамаша кысаларында эшләсәң, ул һичшиксез ныклап торып җәлеп итәчәк. Хәзер сәхнәдәге экранда видеоязма файдалану да бик актуаль. Җырланган җыр белән экрандагы видеорәт, сюжетлар бер-берсен тулыландырып, бербөтен булып бара.

Булган мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмыйча, файдалана белү зарур. Соңгы елларда без Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов теләктәшлегендә «Туган телем – татар теле» дип аталган әдәби-музыкаль проект булдырдык. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә исә 2017 елдан бирле «Татар фольклоры буенча сәнгать дәресләре» биреп киләбез. Боларны без матурлык үрнәгендә тәрбияләү, халкыбызның җан тибрәлешләрен бала күңеленә салу дип, алга карап эшлибез. Мәктәп балалары алдында ясаган чыгышларыбыз вакытында җырлап, биеп кенә калмыйбыз, мин анда уен кораллары турында да шактый күп мәгълүмат бирәм, балалар инструментларны кулларына тотып уйнап та карыйлар. Сәнгатьнең телебезне, милләтебезне саклауга керткән өлеше дип бәяләргә кирәк моны. Шушы дәресләребез барышында яшь буынга сихерле-серле милли

аһәңнәребезнең ни дәрәҗәдә тәэсир итүен, тарихи тамырларыбыз белән кызыксынулары арта баруын күзәтәбез. Балалар безнең белән бергә сәхнәгә үзләре дә менә.

Бөтен төрки халыкларда да давыл дигән уен коралы бар. Әйтик, Казан урамнарының берсеннән кырыклап шундый уен коралында уйнап килсәләр, ул чыннан да давыл купкан кебек булачак. Без ул уен коралын барабан дип йөртәбез. Элгәре әбиләребез, елга буйларында кергә әз-әзләп көл сибә-сибә, кер юганда кулланыла торган кырлы бәләкнең дә үз көе бар. Һәммәсен күрсәтәм, тарихын сөйлим. Гарәп Әмирлегендә чыгыш ясаган вакытта Һиндстаннан килгән бер музыкант бүләк иткән кызык кына уен коралыбыз бар. Анысын да күрсәтәм. Тыштан безнең тальян гармунга охшаса да, үзе шакылдавык сыман. Шунысы сөендерә: балалар ис-акыллары китеп тыңлый. Шул рәвешле үзебезнең милли аһәңнәребез аша яшь буын күңеленә оеткы сала алабыз икән, ул – инде зур эш. Без – үзебез дә өлкән буынның тальян моңнарын тыңлап үскән кешеләр. Шуңа күрә дә фольклор юнәлешендә эшләүчеләргә бу юлдан тайпылырга ярамый.

### «КАРА УРМАН»НЫҢ СЕРЕН АЧТЫМ

Вакыт үтү белән бүген милли рухта иҗат ителгән җырлар да чор сынавын узып фольклор буларак кабул ителер дип уйлыйм, чөнки аның элеккегеләрен дә кемдер иҗат иткән, берсе дә күктән төшмәгән. Үзе бер ядкяр булган «Кара урман» җырын гына алыйк. Илһам абый исән чагында «Бу җырны каян алган идегез?» – дип сорарга җөрьәт итмәдем. Бу соравыма җавап көтмәгәндә үз аяклары белән килде. Могҗиза түгел диген, Алманиянең Лейпциг төрмәсе архивында Беренче бөтендөнья сугышы вакытында татар әсирләренең тәлинкәгә яздырган 100 гә якын язмалары саклanган. Алар арасында әсирләрнең «Кара урман» җыры да бар. Нәкъ Илһам абый җырлаганча, әмма сүзләре башка. Күрәсең, Илһам абый инде аның сүзләрен заманга яраклаштырып җырлагандыр. Шундагы җырларның тагын берсенә бик игътибар иттем. 19 яшьлек егет «Заман» дигән җыр башкара. Эчтәлеге «Эх, заман, заман, ник уятмыйсың син татарларны» кебегрәк. Бу җырга без Башкортстанда иҗат итүче бик сәләтле клипмейстер Рияз Исхаков белән кечкенә генә документаль фильм да эшләдек. Ул хәтта Европага барып, татар әсирләренең кабер ташларына кадәр төшереп кайтты. Бүген инде мин «Эх, заман, заман» дип бары тик татар халкының дөнья күләмендә эш итүче милләт булуына горурлана гына алам. Һәрбер кулга кергән материал шулай бөртекләп, хасиятләп эшләнсә генә күңелдә кала. Нигезендә фольклор әсәрләр яткан 30 га якын шундый клибыбыз бар. Без – шул әсәрләрне иҗади интерпретацияләп түкми-чәчми халкыбызга кире кайтаручылар. Хәзер аларны интернет, мәгълүмат каналлары аша тамашачыга җиткерү бик тә зарур. Бу эшнең ни дәрәҗәдә кыйммәтле, кирәкле гамәл булуын заманында Илһам ага Шакиров бик ачык итеп: «Милләт үзенең сәләтен, байлыгын белсә, аның йөрәге ешрак тибә, горурлыгы арта, ә горурлык булганда милләт яши. Һәр халык, һәр ил, һәр милләт үзенең кем икәнлеген белдерер өчен гомер кичерә, иҗат итә», – дигән иде.

Менә хәзер Сабантуйлар башланып китте. Безне бер барган җиргә кабат-кабат чакыралар. Бу юкка түгел, чөнки тамашачы – мәйдан халкы белән аралашу бара. Безгә кушылып җырлый, бии халык. Кайда гына чыгыш ясасак та, без ихлас, без уйнамыйбыз, без ничек бар шулай сәхнәдә яшибез, күңелләребез ачык, чиста. Айдар Фәйзрахманов һәм Татарстан Республикасының фольклор музыкасы дәүләт ансамбле ул бербөтен. Без – универсаль коллектив. Бер үк вакытта җырлыйбыз да, биибез дә, уен коралларында да уйныйбыз. Дөрес, алдарак телгә алынган гөсләләребезне ерак юлларга, гастрольләргә йөртә алмыйбыз, әмма безнең тальян гармуннарыбыз, сазларыбыз, думбраларыбыз, курайларыбыз бар.

Алга таба эшлисе эшләр шактый. Фольклор материаллар да бик күп, әмма, әйткәнемчә, меңләгән язма арасыннан энҗе-бөртекләре сайлап алыр өчен җиз иләктән иләү мөһим.
Шул рәвешле күп дигәндә бишне, унны тапсаң сөенәсең, әле аны сәхнәгә чыгарлык итеп, «имгәтми генә» сәнгати дәрәҗәгә җиткерәсе дә бар.



## ӘТКӘЙ АЛГАН МОҢЛЫ БИШЕК...

Әле күптән түгел генә Кушлавычтан Тукаевлар музей-йортыннан, Кырлайдан кайтып килүче 20 дән артык хатын-кыз (Башкортстанның «Сәхипҗамал» оешмасының) минем авылым Арча районы Урта Бирәзә авылындагы төп нигеземә килеп керделәр. Музей күрергә килгәннәр. Өйнең бер зур гына бүлмәсен музейга әйләндергән идем. Анда кеше яшәми, үзебез, балаларыбыз кайтып йөри. Шәҗәрәмне барлагач, шул ачыкланды: Әбүбәкер бабам бирегә 1741 елны Әтнә районыннан килеп утырган булган. Музейда 200 гә якын экспонат һәм алар барысы да шушы нигез белән бәйле, читтән кергән бер генә нәрсә дә юк. Мин тугач, әтием Арча базарыннан алып төшкән (әтеп йөри торган) бишек тә, әниемнең безгә пальтога кадәр тегеп кигергән тегү машинасы... Әтиемнең эш коралларының һәммәсе бик кадерле. Чалгыны чалгы пычагы белән кырып, аннан да остарак итеп, борчак чабарга әзерләгән кешене мин белмим. Әтиемнең 60 яшенә (1969 ел) район тарафыннан бүләк ителгән «Рекорд» радиоалгычы да – шундый ядкярләрнең берсе. Мин ул вакытта 7 нче сыйныфларда укыйм. Илһам абыйның яңа гына чыккан пластинкаларын куям да ләззәтләнеп тыңлап ятам. Шушы пластинкалар үз вакытында минем җырчы буларак камилләшүемә, милли моңнарыбызга, фольклорыбызга килүемә зур йогынты ясаган. Ирексездән, «Арча көен» тыңлаганда, күңелем тулып идәндә елап яткан мәлем күз алдына килә. Шулчак: «Улым, нәрсә булды?» – дип, әнием керә. «Берни булмады, әни, күңелем тулды», – дим. Илһам абыйның җырлавы ул үзе бер могҗиза иде. Шул ук вакытта Әлфия Авзалова, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйроваларның милли аһәңнәрен югалтырга ярамый безгә. Асылыбыз, моңлы яңгырашыбыз сакланырга тиеш.

**Фотолар Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивыннан**

# «АПУШ»ЛЫЛАР ТАТАР ДӨНЬЯСЫНДА КАЛАЧАК

Рузилә МӨХӘММӘТОВА





**Балалар театр студияләре, мәктәп театр түгәрәкләре республикабызда гомер-гомергә булган һәм аларны бергә җыеп күрсәтә, алга таба иҗат итәргә стимул бирә торган фестивальләр дә байтак: «Идел-йорт» һәвәскәрләр театр фестиваленең «энекәше» булган «Идел-кәем» балалар театрлары фестивале, «Сәйяр» мәктәп театрлары фестивале, Минзәлә төбәгендә Шаймарданов исемендәге балалар театр фестивале, Әтнә төбәгендә Гомәр Мәрданов исемендәге балалар театр фестивале һ.б. – болар барысы да балалар дөньясының матур бизәге. Шушы гөрләп торган балалар театрлары дөньясында «Апуш» балалар театр студиясе барлыкка килде һәм ул... балалар дөньясына сыеша алмыйча, үзенә аерым игътибар таләп итә башлады.**

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, быел «Тантана» театр премиясе тапшыру тантанасындагы чыгышын «Апуш»ның уңышлары белән башлап: «Театр дөньясында да башка өлкәләрдәге кебек дәвамчанлык әһәмиятле. Шуңа күрә аеруча зур шатлык белән хәбәр итәм: бүген Идел буе федераль округының театраль бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды һәм безнең «Апуш» театр студиясе беренче урын алды. Бу – зур җиңү!» – дигән икән, ә студиянең уңышын Әтнә театрына җыелган бер зал театр әһелләре сәламләгән икән – монысы да зур җиңү. Димәк, «Апуш» театр студиясе балалар театрлары орбитасыннан чыгып, үз орбитасын булдырып килә.




«Апушның тылсымлы төшләре» спектакле (Равил Бохараев пьесасы)

«Апуш» ике ел элек Казан мәдәният идарәсе карамагындагы оешма буларак теркәлде.

Студиянең төп идеясе – киләчәк буынның шәхси, профессиональ һәм иҗади үсеше.

Студиянең төп максаты – укучыларда татар теленә кызыксыну уяту, яшьләрнең иҗади сәләтләрен ачу, милли мәдәниятне үстерү.

Студиядә укучының артистлык потенциалы ачыла, үзенә ышанычы арта, халкының бай мәдәнияте белән таныша, сәнгатькә тартыла. Лидерлык сыйфатларын үстерә, фикерен татар телендә грамоталы итеп белдерә алу күнекмәләренә ия була.

Казан шәһәрләре мәдәният сарайларында эшләп килгән алты студиянең һәрберсе ел саен ук спектакль чыгармаса да, репертуарында дистәдән артык спектакль бар. Әлбәттә, аларның һәрберсе дә бүген тотып күрсәтерлек була алмый, чөнки балалар үсә тора, студиядән китә тора, алар урынына яңалары килә. Профессиональ театрлардан аермалы буларак, «Апуш» балалар театр студиясенең төп продукциясе – спектакль чыгару түгел, балаларга бирелгән белем һәм үз халкының бай мәдәнияте, традицияләре белән танышуга, милләтеңне яратуга юнәлтелгән бер максат тирәсендә берләшергә өйрәтү. Спектакльләр исә студия алдына куелган максатларның матур бонусы булып тора. Дөресрәге, олы юлдагы күпсанлы үрләрнең берсе – балаларны бергә туплый һәм дуслаштыра, җыештыра-оештыра, 24 сәгатьлек тәүлекнең һәр сәгатен, һәр минутын кадерләргә өйрәтә, гомумән, дөньяны бизи торган бер матур чара.



**Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Апуш»лылар белән**



**Булат Гатауллинның Гөлүсә Батталова пьесасы буенча куйган «Тукай. Ярлыкагыл» психологик драмасы. Нәни Апуш ролен башкаручыларның берсе – Сәйдәш Гарифҗанов**

Әйдәгез, шул бонус-спектакльләренә күз салып узыйк.

«Апуш» студиясенең беренче эше – Равил Бохараевның Тукай иҗатына багышланган «Апуш»ның тылсымлы төшләре» спектакле. **Спектакль «Сәйдәш» мәдәният үзәге сәхнәсеннән күрсәтелде**, чөнки «Апуш» шушы мәдәният үзәгендә башланып, Казанның башка залларын да «яулап алды».

Соңрак «Апуш»ның шул ук «Сәйдәш» мәдәният сарае филиалында «Зоопарк-әлифба» (Йолдыз Шәрапова, Хәбир Ибраһимов инсценировкасы), «Кар иле патшабикәсе» (Андерсенның «Снежная королева» әкияте нигезендә Евгений Шварц пьесасы) спектакльләре чыкты. Филиалның яңа эше – Гөлүсә Батталова пьесасы буенча куелган «Көндәлек» спектакле. Әлеге студиянең «йолдызы» Иван Пугачёв хәзер Казан театр училищесында – Зөлфәт Закиров курсында белем ала, быелдан башлап Кариев театры репертуарындагы «Куркак батыр» спектаклендә төп рольне Булат Гатауллин белән чиратлашып уйный башлады.

**«Апуш»ның икенче филиалы «Чулпан» мәдәният үзәгендә ачылды** һәм беренче эш итеп алар күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» әсәренә алына. Төрле театраль фестивальләр лауреаты булган «Авыл эте Акбай» спектакле дә шушы филиал эше. Филиалның әр-яңа эше – «Елантау» музыкаль әкияте (авторы – Резеда Зәйниева) Камал театрының Кеңчыгыш залында күрсәтелде.

**«Апуш»ларның Ленин исемендәге мәдәният сараендагы филиалы** быел «Мәкәрҗәдә театр» спектакле белән «Театраль Идел буе» фестивалендә «Иң яхшы балалар спектакле» номинациясендә җиңеп чыкты. Балалар спектакльләре арасында «Иң яхшы режиссёр эше» номинациясендә спектакльнең режиссёрлары, актёрлык осталыгы һәм сәхнә теле остазлары – Татарстанның халык артисты Зөлфия Вәлиева һәм Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Шәйхетдинова җиңү яулады. «Иң яхшы сәнгать бизәлеше» номинациясенә спектакльнең сценографы, рәссамы – Татарстанның Рәссамнар



Гөлүсә Батталованың «Көндәлек» пьесасы буенча Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан куелган спектакль

берлеге әгъзасы Анастасия Бузунеева лаек булды.

Шунысын да әйтергә кирәк: «Апуш»лылар әлеге фестивальдә 2023 елда «Апушның тылсымлы төшләре» спектакле («Сәйдәш» мәдәният үзәге) белән – I урын, 2024 елда «Кечтүк» спектакле (Ленин исемендәге мәдәният сарае) белән – II урын, 2025 елда «Авыл эте Акбай» спектакле («Чулпан» мәдәният сарае) белән I урынга лаек булды.

«Мәкәрҗәдә театр» спектакле Татарстанның атказанган артисты Илтөзәр Мөхәммәтгалиевнең татар пьесалары мотивларын кулланып язылган инсценировкасы буенча куелган. Карадым мин ул спектакльне, легендар шәхесләребез Әзһәр Шакиров һәм Рабит Батулла белән бергә гаҗәпләнеп һәм сокланып карадым.

«Әлеге балалар шулхәтле матур тәэсир калдырды: үзләренең татар икәнен аңлап чын татарча эшлиләр. Килгәндә болай булыр дип уйламаган идем. Татар театры юкка чыгу мөмкин эш түгел, аның чиге юк», – дип, фикере белән бүлеште **Әзһәр Шакиров**.

**Рабит Батулла**, аңа кушылып: «Мин көнләшеп утырдым. 86 яшькә җитеп, бу эшне эшләмәгәнемә үкенәм. Ләкин минем теләгемне үтәделәр. Балалар, ут чыгарып, профессиональ дәрәҗәдә уйныйлар. Музыка, сәхнә бизәлеше, актёрларның уены, тамашачылары да – барысы да искиткеч», – диде.

«Мәкәрҗә...»гә кадәр әлеге иҗади төркем Илгиз Зәйниев пьесасы буенча «Кечтүкле уен» спектаклен чыгарды. Бүгенге көн балалары тормышын фэнтези белән кушкан кызыклы драматургия һәм аның «Апуш» педагог-режиссёрлары Зөлфия Вәлиева һәм Миләүшә Шәйхетдинова тарафыннан кызыклы чишелеше таң калдыра.

**«Апуш»ның «Московский» мәдәният үзәгендә ачылган филиалы** үз эшчәнлеген режиссёр-педагог Зөлфәт Закиров белән бергә Шамил Фәрхетдиновның «Әкият китабы» спектакленнән башлады. Ике ел дәвамында әлеге спектакль белән чарлангач, иҗади команда Тукайга күз салды һәм режиссёр-педагог Булат Гатауллин белән «Тукай. Ярлыкагыл!» психологик драмасын чыгарды. Бала вакыттагы үпкә-рәнҗүләр, кайгы-хәсрәтләр гомер буе озата барамы? Чынныктырамы? Бала күңеле авырлыкларны ничек кичерә, аларга ничек каршы тора?



Татарстанның халык артисты Илтөзәр Мөхәммәтгалиевнең «Мәкәрҗәдә театр» спектакленнән бер күренеш

Өлкәннәр өчен дә шактый авыр әлеге сорауларга спектакль балалар йөрәге, балалар теле белән җавап табарга тырышты. Гөлүсә Батталова ярдәмендә, әлбәттә – автор ул.

Шагыйрә Гөлүсә Батталова – «Апуш»ның якын дусларының берсе: беренче эшләреннән башлап аның шигырьләре озата бара, юбилей инсценировкаларын да ул ясый.

«Апуш» студиясендәгеләр үзләре әйтмешли, «Мәскәүскиләр» турында язганда, әлеге филиалда шөгыльләнүче Сәйдәш Гарифҗанов турында әйтми кала алмыйм. «Әкият китабы» аша игътибарны җәлеп иткән егет Кариев театрының «Куркак батыр» спектаклендә катнаша. Әлмәт театры оештырган драматургия лабораториясендә чыккан «Кадерлем» пьесасы буенча эшләнгән эскизда катнашып, үзенең импровизацияләре белән дә комиссия әгъзаларын таң калдырды ул.

**2025 елдан «Апуш»ның тагын бер филиалы Дәрвишләр бистәсендәге Сәетгалиев исемендәге мәдәният сараенда** ачылды. Бу – Казанда татар телендә халык театрын саклап кала алган урын. Шуңа биредә балалар театр студиясе ачылуы да табигый. «Апуш»ларның яңа төркеме эшне Илфак Хафизовның «Сарымсак» дип аталган әр-яңа әсәреннән башлады. Режиссёр һәм педагог – Резеда Гарипова. Балалар җитди темага алынган: катлаулы карарлар кабул иткәндә ничек намуска тугры калырга, җаваплылык юкка чыга баручы күренешме, әллә кешелекнең төп сыйфатымы? Спектакль шушы катлаулы проблемаларга, сорауларга җавап эзли. Шулай итеп, яңа драматургиягә алынырга профессиональ дәүләт театрлары да куркып торганда, балалар моңа кыю алына, афәрин!

Нигездә, мәктәпкәчә яшьтәге балалардан торган нәниләр төркеменең эше белән, ни кызганыч, танышып өлгерә алмадым. Ә алар Камал театры сәхнәсендә үз иҗатларын күрсәтеп өлгерде инде. Казан Мэриясенең «Алмачуар» балалар һәм яшүсмерләр аудиториясе өчен татар телендә язылган пьесалар конкурсында җиңү яулаган «Тыз-быз» пьесасы (автор Айгөл Әхмәтгалиева) буенча спектакль чыгарды алар. Нәниләр белән тәҗрибәле остазлар – актёрлык осталыгыннан Гүзәл Сибгатуллина, Гөлназ Нәүмәтова, вокалдан Алсу Фәйзуллина, сәхнә хәрәкәтеннән Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты Алсу Мәгъсүмҗанова шөгыльләнә.

* * *

«Апуш»лылар Казан шәһәре башлыгы урынбасары Гүзәл Сәгыйтованы «студиянең әнисе» дияргә ярата. Әйе, театр студиясе Алия Фәйзрахманова белән Гүзәл Сәгыйтованың фикердәшлегеннән туган. «Бервакыт Резеда Сәлахова белән бергә самолётта очарга туры килде. Сөйләшеп киттек, мин уйларымны сөйләдем. Ул миңа Гүзәл Сәгыйтова янына барырга киңәш итте. Килдем, тыңлады... Кариев театрында эшләгәндә үк аңарда балалар театр студиясен булдыру идеясе булган. Күрәсең, Ходайдан сәгате җитмәгәндер дә, кешесе булмагандыр», – дип сөйләгән иде Алия Фәйзрахманова.

«Апуш» балалар театр студиясе булса да, аның миссиясе һич кенә дә театр кую белән генә чикләнми, әлбәттә. Миңа калса, бу гомумән, беренчел түгел һәм студия Казан театр училищесы өчен студентлар әзерләүче курслар да түгел. Ә бәлки югары сыйфатлы татарлар әзерләүче студия. Югары сыйфатлы диюем, татар телен белгән кызларыбызның-малайларыбызның рухи тормышы татарның гореф-гадәтләрен, йолаларын белүе белән, татар мәдәнияте-сәнгате белән кызыксынып ныгытылган, киләчәгенә милли горурлык орлыклары салынган була. Дөньяның кайсы почмагында гына яшәсәләр дә, алар татар дөньясында калачаклар – «Апуш» шуны гарантияли кебек.

«Апуш» – әлбәттә, тел сагында торган оешма да. Безнең бит инде Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе эшләп килә һәм ул бик күптөрле проектларны дөньяга чыгарырга ярдәм итә. Ул проектларның һәркайсының «кипиай»ын (KPI) санаучы бардырмы-юкмы һәм аны санау мөмкин эшмедер-юкмыдыр – белмим, әмма «Апуш» – тәгаен тел сагында торучы проект. Комиссиябез беренче чиратта аларга булышсын иде. Хәер, «Апуш»ны спектакльләре аша яхшы белгән комиссия җитәкчесе Марат Готыф улы үзе дә моны яхшы аңлый.

«Апуш» һәрвакыт татарча гына булачакмы?» – дип сораган идем бервакыт студия җитәкчесе Алия Фәйзрахмановадан. «Әйе. «Апуш» – татар балалар театры студиясе, «Апуш» – ул татарчалык, – дип җавап биргән иде ул.

* * *

А. Фәйзрахманова белән KPI хакында

***– Спектакль чыгару арзан түгел. Сез акча бирүчегә – аерым алганда, мэриягә һәм, пафослы итеп әйтсәк, милләткә нәрсә гарантиялисез? Җиңүләр белән горурлану, ә тагын? Алар өчен әҗере нәрсәдә?***

– Аларга нәрсә әҗер дә, халыкка нәрсә әҗер, дип уйласак, бездә балаларны тәрбияләү һәм татар телен үстерү беренче урынга куелган. Ә фестивальләргә килгәндә, болары матур кушымта кебек.

***– Ягъни, түрәләр өчен матур «галочка».***

– Әти-әниләрнең рәхмәтле булулары, татар баласын тәрбияләү – әҗер шул. Татар баласының үзен татар дип кабул итүе мөһим. Монда язылган гарантияләр юк. Без түрәләребезне премьераларга чакырабыз, һәм аларга нәтиҗә ошый. Алар тотылган акчаларның сыйфатлы нәтиҗәләргә китерүен күрәләр. Саннар да шуны раслый – кастингка килүчеләр саны арта.

***– «Апуш» студиясе балаларга татар теленең кирәклегенә ышаныч тудыра аламы? Татарча белсәм генә анда алалар, дигән кызыксыну?***

– «Апуш» театры – татар балалары театры. Бала аны карый да: «Минем дә анда уйныйсым килә, ләкин мин, анда уйнау өчен, татар телен белергә тиеш», – ди. Ата-аналар: «Без «Апуш»ка эләгү өчен нишләргә тиеш?» – дип шалтыраталар. «Апуш»ка эләгү өчен балагызны «Апуш» белән таныштырыгыз – спектакль карагыз», – дим. Баланың үз мотивациясе булырга тиеш. Теле шома булмаса, шомартырга, телефонга татарча шрифт куеп, татарча язышырга кушам. Без үзара татарча сөйләшергә тырышабыз. Берәр спектакль белән автобуста барсак, алар, безне уздырып, татарча җырлыйлар. Чараларда, безнең балаларны «Апуш»ныкылар дип әллә каян таныйлар. Миндә милли хисләр һәрвакыт булса да, ләкин элек ул миллилекне миссия дәрәҗәсендә кабул итү булмагандыр. Барысы да табигый бара иде, ул хакта аерым уйланылмаган. Хәзер «Апуш»та үзеңнең татар икәнеңне кабул итү миссиягә әверелде булса кирәк.

# ЧӘЧӘКЛӘРНЕ *«колагыннан» тартып*



Расиха ФАИЗОВА

***Тасмалардан эшләнә торган бизәү алымын руслар колакка охшатып булса кирәк, «ушковая техника» дип атаганнар, шуңа ияреп «колак сыман чигү» диючеләр дә очрый. Чынлыкта исә XVIII гасырдан ук мәгълүм һәм татарларга гына хас әлеге бизәү ысулын «тырнак алмалау» дип атыйлар. Шундый алым белән башкарылган эшләнмәләрне без Татарстан Республикасы Милли музеенда да күрәбез.***



Алар үзләренең купшылыгы, затлылыгы, башкару осталыгы белән таң калдыра. Нәкъ менә шуларны күргәч, символ-тамгаларга корылган гаҗәеп паннолар иҗат итүче кулланма гамәли сәнгать остасы, Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты Земфира Бикташева: «Мин моны өйрәнәчәкмен һәм сәнгатебезгә кире кайтарачакмын», – дип, күңеленә беркетеп куя һәм шактый еллар тырнак алмалауны да кертеп катнаш техникада милли рухлы паннолар иҗат итә. Дөрес, аңа кадәр дә әлеге алымны кире кайтаруга омтылыш була. Башлыча керәч (керамика) юнәлешендә иҗат итсәләр дә, Нина Кузьминых белән Ирина Макарова да алына бу эшкә. Аларның атлас тасмалар белән бизәлгән бәрхет диван мендәрләре бүгенге көндә инде музейларда саклана. Санкт-Петербургтагы Россия этнография музеенда узган «Традиция һәм мода» күргәзмәсе (1990) өчен махсус эшләнгән була алар.

– Әле булса әнинең ул техникага төшенер өчен китапханәләргә йөргәнен, шактый эзләнгәнен хәтерлим. Күрәсең, ашыгыч рәвештә миллилек бөркелеп торган экспонатлар кирәк булгандыр. Вакыт белән исәпләшмичә шактый мендәр эшләде алар. Мин үзем дә таҗлар ясаштым ул чагында, – дип хәтер яңарта Нина Васильевнаның кызы флорист-декоратор Александра.

## ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ӨЛЕШЕ

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан һәм Евразия Рәссамнар берлекләре әгъзасы Әлфия Рәшит кызы Нурхәмәтованы да заманында кулына энә-җеп, ефәк тасмалар алырга әлеге дә баягы музейдагы шул гаҗәеп экспонатлар этәргән булып чыкты. Казанда Нурзия Сергеева уздырган осталык дәресендә катнашканнан соң (2013 ел), үзен бу өлкәдә сынап карыйсы килү теләге тагын да ныгый. «Ул эшләрнең ни дәрәҗәдә катлаулы булуына карамастан, югары кимәлдә башкарылуына торып-торып ис-акылларым китте», – ди ул. Башта атлас, аннан органза тасмалар белән ясап кулын күнектерә. Җебен-җепкә, җеген-җеккә китерә торгач, катлаулы алымның асылына төшенеп, музейда күреп тәмам гашыйк булган калфакка реконструкция ясарга җөрьәт итә. Һәм, ниһаять, үзе өчен өр-яңа «ефәк юлы»н да ача! Ефәк тасмалардан эшләнгән бизәкләр тагын да затлырак, саллырак килеп чыга башлый. Ул җитәкләгән музейның «тырнак алмалау техникасын торгызган» өчен ТР Мәдәният министрлыгының грантына ия булуы да күңелен үстереп җибәрә. Уңыш озак көттерми талымлы остаы, калфаклары бер-бер артлы республика дәрәҗәсендә күренә башлый. «Алтын хәситә» Халыкара конкурсына тәкъдим иткән эшләре (2020) югары бәя алып, Мәскәүдә һәм Татарстан шәһәрләрендә узган күргәзмәләрдә күрсәтелә. «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» конкурсы лауреаты (2023) бер елдан соң Россия сәнгать атнасы кысаларында узган XXXVI халыкара заманча сәнгать күргәзмәсенең «текстиль» бүлегендә II урын яулый. ТР Мәдәният министрлыгы Гаилә елына багышлап игълан иткән «Тылсымлы җеп» конкурсында I дәрәҗә лауреат буларак танылу да Әлфия Нурхәмәтовага канатлар куймый калмагандыр. Күргәзмәләр, конкурслар, әнә шулай берсе икенчесенең үкчәсенә басып килә. Өлгер генә! Иң сөендергәне остаың тырнак алмалау ысулын кулланып башкарылган эшләнмәләренең



**Әлфия Нурхәмәтова**





Әлфия Нурхәмәтованың кул эшләре күргәзмәдән-күргәзмәгә күзгә күренеп җетеләнә бара





**«Гөлләрем, гөлкәйләрем».**
**Бәрхет, ефәк тасма, сәйлән, пайетка, чигү**

төрләре елдан-ел арта бара. Әлфия ханым иҗат иткән үтә дә купшы, нәзакәтле калфак, букча, китап тышлары, декоратив мендәрләр, акча янчыклары, камзуллар, рельефлы композицияләргә корылган панноларның инде исәбе-хисабы юк. Аның эшләре үзебездә генә түгел Төркия, Кытай, Казахстан, Азәрбайҗан, Чечня, Катар, Үзбәкстан, Башкортстан һ.б. җирләрдә узган күргәзмәләргә куела, шәхси тупланмаларда саклана. Шул рәвешле рәссам мәдәниятебезнең, сәнгатебезнең уникальлеген, затлылыгын халыкара дәрәҗәдә дә таныта. Әйтүе генә җиңел, Татарстан Республикасы дәүләт җыр һәм бию ансамбленең бер комплект костюмнары – озын җиләннәр, калфаклар тулысынча ул атлас тасмалардан ясаган чәчәкләр белән бизәлә. Бер елга сузыла бу җаваплы эш.

Хәер, Әлфия ханым, ике дистә елдан артык башка өлкәләрдә (башта 15 ел Аксубай сәнгать мәктәбендә укытучы, аннан тугыз ел районда төбәкне өйрәнү музейлар челтәре директоры) эшләгәннән соң, 2022 елда тәвәккәлләп иҗат юлын сайламаган булса, эш арасында гына хәзерге шикелле иркенләп, кинәнеп иҗат итә алыр идеме икән? Әйтүе кыен. Ни генә булмасын кайчандыр Лениногорск сәнгать көллиятен, Чаллы пединститутының худграфын тәмамлаган рәссам тормышының мондый борылыш алуына һич кенә дә үкенми, чөнки үз көймәсендә, үзенең иҗат диңгезендә ул бүген. Хәзер инде аның өе үзе бер остаханәне хәтерләтә. Этажерка, өстәлләр берсе дә буш түгел – һәркайсында материаллар останың тылсымлы куллары орынганын көтеп ята. Кайсысын буярга, кайсысын чигәргә дигәндәй...

Сүз иярә сүз чыгып, Әлфия ханымның кул эшенә хирыслыгы нәселдән килүе дә ачыклана. Әтисе ягыннан Мәхмүт бабасы заманында тирә-якта дан тоткан балта остасы булган икән.

– Бабамнар үзләренең Карасу авылында кибет тотып, анда тукыма, керосин ише кирәк-ярак белән сату иткән. Кулак дигән мөһер сугып, бар булган мал-мөлкәтләрен талап алып, Комсомольск-на-Амурега сөргенгә сөрелүләренең сәбәбе шул була. Аннан кабат авылга кайткач та, буфет, урындык ише йорт җиһазлары, тараклар ясавын дәвам иткән бабам. Әбием исә, мендәр тышын капчык итеп, шул таракларны тутырып, Чистай базарына сатарга йөри торган булган...

Менә шундый кулларыннан эш килә торган нәсел дәвамчысы Әлфия Рәшит кызы. Булсын дип, тел-теш тидермәслек итеп эшли һәм үз дигәненә ирешә торганнардан. Аның кебек чәчәкләрне «колакларыннан» тартып «үстерүчеләр» дә бармак белән генә санарлык шул.

**Автор фотолары**



# Түш каптырмасы

Иң элек нәрсә эшлисебезне планлаштырабыз, булачак эшләнмәнең эскизын кәгазьдә сызу мөһим. Калфак буламы ул, китап тышлыгымы җирлек (фон) белән тасмаларның төсе аваздаш булып, яраштырып килергә тиеш. Гадәттә композициянең үзәгендә зуррак, ян-якларында кечерәк бизәкләр планлаштырыла. Бу юлы без бер генә бизәктән торган түш каптырмасы, ягъни брошка ясарбыз.


## Кирәкле материаллар

Җирлек өчен юка киез (фетр); шифон, я булмаса ефәк тукыма, яки атлас тасма; кайчы, энә, җеп (энәне тасма төсендәге җеп белән саплыйбыз).

## Эш барышы

Иң элек җирлек өчен үзен тотардай тыгызрак фетр алып аннан булачак каптырманың нигезен кисәбез. Ул безнең өч таҗлы лалә чәчәге рәвешендә булачак.

Аннан соң тукымадан 2 – 2.5 см киңлектәге тасмалар кисәбез. Тасма киңлеге кечерәк булган саен бизәкләр нәфисрәк булачак. Чәчәк таҗы килеп чыксын өчен, тасманы шакмаклап кисәбез. Кечкенә тукыма кисәгенең ике почмагын башта кара-каршы китереп куябыз һәм ике як «очрашкан» җирне эчкә каратып урталай бөклибез. Килеп чыккан бөкләмнең очы калырлык итеп тагын берсе өстенә икенчесен кара-каршы китереп бөклибез. Ягъни таҗ килеп чыксын өчен тукыма кисәген без өч тапкыр бөкләдек булып чыга. Килеп чыккан таҗыбызны фетрга энә белән тегеп куябыз. Алга таба да шул рәвешле эшлибез. Лаләнең башта бер, аннан икенче, өченче таҗларын эшлибез. Каптырмабыз күзгә күренеп купшылана барачак. Таҗларны беркетеп бетергәннән соң, җөй урыны күренеп тормаслык итеп яшел пайетка, я булмаса канитель белән каплап куябыз. Каптырмабыз теләсә кайсы киемне, яки аксессуарны бизәп торачак.



**Автор фотолары**

# Орчык өмәсе

**Алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Татар халкының тәрбияви һәм әхлакый әһәмияткә ия булган, буыннан-буынга күчеп бара торган йола-бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре шактый. Кызганыч, аларның кайберләре заманалар узу белән вакыт тузаны астында кала килә. Шул исәптән бер-беребез белән очрашуга бер сәбәп булып торган кич утырулар да сирәгәя.

Бүген без сезне әнә шул онытылып бара торган йолаларыбызның берсе булган «Орчык» бәйрәменә чакырабыз.

**Әби.** Бабагыз өмәчеләрне алып киләм дип киткән иде, үзе дә юк, өмәчеләр дә күренми. Түбән оч Харисны очратып, шуның белән гәпләшеп тора микән?

Кеше-кара килгәнче кабамны, орчыкларымны әзерләп куярга кирәк.

*Гармун тавышы ишетелә. Бүлмәгә бабай белән өлкәннәр керә.*

**Әби.** Менә бит, рәхмәт яугыры. Киләләр. Самавырымны гөрләтеп җибәрим әле.

**1 нче өмәче.** Исәнмесез, хуҗалар!

**Әби.** Аллага шөкер, әйдә түрдән узыгыз, өмәчеләр. Нишләп болай соңга калдыгыз?

**Бабай.** Кәчкә алып килдем. Әйдәгез, әйдәгез, кунаклар, җайлап кына урнашыгыз.

**2 нче өмәче.** Яшьләр, балалар күренми бит әле. Алар да килеп җитсеннәр иде инде. Өмәне башлар идек.

*Утыралар.*

**3 нче өмәче.** Әйдәгез, без эшне башлый торыйк, балалар килеп тә җитәрләр, узып та китәрләр алар. *(Кемдер йон эрли, кемдер йон яза. Бабай пәке белән кырып орчык ясый.)*

**1 нче өмәче.** И-и замандаш, гомер буе шулкадәр матур, тигез итеп эрләдем. Ул орчыкның сере беләсеңме нәрсәдә? Синең картың ясап бирде бит аны миңа, күр әле, ничек итеп үзеннән-үзе эшли.

**Әби.** Үзенең карчыгына орчык ясамыйча, күршегә ясап йөри икән әле.

**Бабай.** И-и карчык, сиңа дип атап ясап утырам бит менә. Тукта, самавырны карап керим әле. *(Чыгып китә.)*

**Әби.** Кая соң безнең балалар, нишләп күренмиләр икән?

**2 нче өмәче.** Әйе шул, аларга эш тәртибен аңлатып, өмәне бергәләп башлап җибәрсәк, хәерлерәк буласы иде.

*(Гармунчы белән балалар җырлап керәләр.)*
*Җыр: «Матур булсын».*

**1 нче бала.** Менә сездә өмә икәнен ишеттек тә дуслар белән җыелып килдек.

**Әби.** И-и, рәхмәт инде,балалар, әйдәгез узыгыз, җайлашып утырыгыз.

**1 нче өмәче.** Әйдәгез, эш башланганчы, йортка дога кылыйк. *(Дога укыла бергәләп.)*

**2 нче өмәче.** Эшләребез җиңелләрдән булсын, тиз-тиз генә эшләп алыйк.

**2 нче бала.** Апалар, аңлатыгыз инде безгә Орчык өмәсенең хикмәтләрен?

**Әби.** Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп, диләр иде безгә әби-бабайлар. Орчык өмәсе – безгә ата-бабаларыбыздан калган мирас ул. Аны гадәттә кышкы озын кичләрдә уздырганнар. Шулай да чананы җәйдән әзерлә дияргә ярата бит безнең халык. Оекбаш, бияләй хәстәрен алдан күреп куйсак та зыян итмәс. Әйдәгез әле, балалар, мин сезгә бик тәфсилләп аңлатып бирим. *(Әкрен генә сандыкны ача.)* Балалар, карагыз әле, сез монда нәрсәләр күрәсез? *(Бияләй, оекбаш.)* Хәзер гадәттә бу әйберләрне кибетләрдән сатып алалар. Ә элек без аларны үзебез бәйли торган идек. Бу бияләй, оекбашларны бәйләү өчен безгә иң элек йон кирәк булачак. Әйтегез әле, балалар, йонны без каян алабыз?

*(Балаларның җаваплары.)*

**Балалар.** Сарык йоны.

**Балалар.** Кәҗә мамыгы.



**Балалар.** Куян мамыгы...

**Әби.** Әйе, бик дөрес әйтәсез. Без чималны үзебез асраган терлекләрдән алабыз.

Бу йоннан *(күрсәтә)* без әле бияләй, оекбашлар бәйли алмыйбыз. Аны башта чистартырга, ягъни язарга кирәк. Менә бу эшне сезгә күрше әбиегез күрсәтеп бирер.

**1нче өмәче.** Балалар, иң элек йонны менә шулай итеп тигәнәк һәм чүпләрдән арындырабыз. Аннан соң без аны чеметеп-чеметеп кенә алып юкартабыз, ягъни язабыз. Әйдәгез, сез дә кушылыгыз әле. Йонны язганнан соң аны тыгызлап җыябыз һәм ул көнҗәлә (гөнҗәлә) дип атала. Әзер гөнҗәләне кабага бау белән бәйләп куябыз һәм менә шулай итеп орчык белән йонны эрли башлыйбыз.

**2 нче өмәче.** Орчык тулгач, әзер җепне йомгакка урыйбыз. Безнең инде оекбаш бәйләргә дигән чималыбыз күзгә күренде дигән сүз бу.

Төсле җеп кирәк булса, аны табигый буяуларга буярга да мөмкин.

**Әби.** Без элек тә өмәләрдә эшләп кенә утырмадык, уеннар да уйный, җырлап-биеп тә ала торган идек. Әйдәгез, сезнең белән шул уеннарның берсен – «Йомгак» уенын уйнап алыйк әле.

*(Уенның эчтәлеге аңлатыла.)*

**3 нче өмәче.** Менә, балакайларым, сез уйнаган арада әзер йомгактан шәл бәйләдем. Карагыз әле, шәлем матур булганмы?

Ягез әле, кызлар, шушы матур шәлләр белән бер биеп алыйк булмаса.



*Җырлы бию: «Шәл бәйләдем».*

**Бала.** Бәйрәмебез бик күңелле бара. Бик күп нәрсәләргә өйрәнсәк тә, без халкыбызның бик күп йолаларын белеп бетермибез икән әле.

**Әби.** Ярый, балалар, без сезгә үзебезнең гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз белән алга таба да таныштырырбыз.

Орчык өмәсендә уйнала торган бер бик кызык уеныбыз бар.

**Балалар.** Нинди уен ул, әбекәй?

**Әби.** Ул «Орчык бөтерү» уены. Мин орчыкны бөтерәм, орчыкның башы кемгә карап туктап кала – шул кешегә җәза бирелә.

*«Орчык бөтерү» уены.*

**Бабай чыга.** И оланнар, өмә булгач, өмә булсын «Орчык такмаклары»н җырламый булмас.

**Өмәчеләр.**
*Әйдәгез, әйдәгез!*
*Йон эрлимен, йон эрлимен,*
*Кил син бездә аулак өй.*
*Орчыклар биеп торганда*
*Түзеп булмый җырламый.*

*Тал тамыры агып килә*
*Түгәрәк күлләренә.*
*Күмәкләшеп без йөрибез*
*Орчык өмәләренә.*

**Бала.** Ярый әле килгәнбез. Никадәрле уеннар, җырлар белеп кайтып китәбез.

**Әби.** Менә, балалар. «Орчык өмәсе» шулайрак үтә инде ул. Эшен дә эшләдек, күңел дә ачтык. Я, сезгә ошадымы соң, балалар?

**Бала.** Бик күңелле булды. Без дә буш килмәдек, сезгә үзебезнең матур җырыбызны алып килдек.

*Җыр: «Куш кулым».*

**Әби.** Ай-һай булдырасыз, балалар! Әйдәгез, хәзер бергәләп табын янына утырышыйк. Эшен эшләгәч, ашы да була аның. Әйдәгез, җитешегез! Аш булсын, тәмле булсын, балалар!

**Рузалия ЛАТЫЙПОВА,**
**Актаныш районы Пучы балалар бакчасы тәрбиячесе**
**Автор фотолары**

# Тәнне яздыру

Эльмир Низамов көе
Резеда Зәйниева сүзләре




*Мин иртә белән торам,*
*Кулларны, битне юам!*
*Аннан зарядка ясыйм –*
*Көнемне шулай башлыйм!*

*Башта кулларны өскә,*
*Аннан куябыз янга,*
*Самолёт булып кына*
*Очабыз әйдә алга!*

*Көч ташып тора минем,*
*Шәп үтә һәрбер көнем,*
*Иртән тәнне яздырсам*
*Һәм вакытында торсам...*

*Идәнгә бөгеләбез,*
*Утырабыз чүгәләп*
*Һәм торабыз сикереп,*
*Тотарга дип күбәләк!*

*Жырлап йөрим көн буе,*
*Гел яхшылыкта уем!*
*Чөнки көн саен иртән*
*Зарядка ясап үтәм!*

*Сикерәбез аякта,*
*Уң якка һәм сул якка!*
*Әйләнәбез йөгереп*
*Һәм басабыз тезелеп!*

# «Щәле коймагы»

Расиха ФАИЗОВА



Ерак әнием (әниемнең әнисе) коймак-тәбикмәкләрне өеп-өеп пешерер иде. Каз өмәсе көнне өмәчеләр эшне бетереп, ашап-эчеп алганнан соң «Барыгыз балаларга дәшегез», – дип, ул күрше-тирә бала-чагасын чәйгә чакырырга кертеп җибәрә. Керәләр, өстәл әйләнәләй утырабыз, пычак тидерми генә икегә бүлгән тәбикмәкләрне каз маена манчып-манчып ашыйбыз. Шуннан да тәмле әйбер юк ул көнне. Үзе калын, үзе йомшак, кояшта пешкән диярсең... Башка бәйрәмнәр җитсә дә, өйдә таба исе чыкмый калмый. Андый чакта син инде өйне кочып алган шул иснең борыныңны кытыклавына уянасың.

Менә шундый балачак хатирәләренә уралып Питрәч районы Шәле авылында яшәүче уңган-булган аш-су остасы Миләүшә Мөхәммәтгалиеваның капка төбенә килеп туктаганны да сизми калганмын. Уңганлык, тырышлык өстенә үтә дә ипле, итагатьле ханым да әле ул. Үзләренең өч баласы үсеп-җитеп туган оядан таралышкач, моннан 19–20 еллар элек шушы бәрәкәтле нигезгә ире Мансур белән балалар йортындагы өч бертуган сабыйны алып үстергән киң күңелле, олы йөрәкле мәрхәмәт ияләре алар. Алты, җиде һәм ике яшь ярымлык кына була алар ул чагында. Ире Мансурның вафатына быел инде ун ел икән. Кайчандыр шау-гөр килеп үскән балалар да хәзер кунак кына бу йортта. Биш вакыт намазын калдырмыйча, мал-туар асрап, авыл тормышы белән көн күргән ханымның моңаеп утырырга вакыты каламы икән? Юктыр, мөгаен, чөнки көндәлек мәшәкатьтән гайре дә ике кулына бер эш табылып кына тора. Кунак-төшем, бәби туйлары, никах мәҗлесе икән – аның мич коймагы пешерүен сорап килә авылдашлары. Ни өчен дигәндә зур мәҗлесләрдә мич коймагының урыны түрдә бирелә. Аны табынга ипи урынына чыгару да гадәти хәл. Әйтик, туйларга аны икешәр чиләк тутырып, кучтәнәчкә алып бару да – матур йолаларның берсе. Хәер, авылдашлары табынында гына да түгел, аның коймаклары Мәскәү, Самара, Сарытауларны узып, Мәккә, Мәдинәләргә кадәр барып җиткән. «Аш булсын!», «Хәерле ризык булсын!» – дип, догаларын укый-укый шушы эшкә тотынуына да 15 еллап гомер узган Миләүшә ханымның.

– Шәхсән үзем мич коймагы пешерү серләрен авылдашыбыз югары очта гомер иткән Тәзкирә апа Хәйруллинадан өйрәндем. Ул гомер буе туйларга камыр ризыклары пешерде. Билгеле беренче тапкыр килеп чыкмый. «Нәкъ синең сыман эшләдем, нигәдер уңмады. Коймагымның асты да, өсте дә килә, эче пешеп бетми», – дип борчылып тагын аның янына киттем. «Синең, мөгаен, мичтә торуы җитмидер» – ди бу. Олылар сүзен капчыкка, яшьләр сүзен янчыкка, дип остазлар сүзенә колак салмый хәлең юк. Ник дисәң, бермәлне коймак табага ябыша башлады. Баксаң, коймак табасы аерым булырга тиеш икән. Аны башка максатта тота, аннан соң юа башласаң, коймакның ябышканын көт тә тор инде.



Мичтән дә уңган хуҗабикә. Аш бүлмәсенең дүрттән бер өлешен диярлек алып торган мичнең дә үз тарихы.

– Бу мичне авылга газ кергәнче үк бөтен Шәләне мичле иткән Госман абый Миндубаев чыгарган иде. Газ кергәч тә, аны сүтү турында уйлаганыбыз да булмады, – ди ул.

Шулай сөйләшә-сөйләшә, Миләүшә ханым белән бергәләп мич коймагы пешерү хәстәренә керешәбез.

## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Коймак камыры өчен кирәк:**
3 литр сөт,
3 йомырка,
3 аш кашыгы тутырып шикәр комы,
1 аш кашыгы тутырып тоз,
2 аш кашыгы майонез,
0.5 л сыек май,
100 г чүпрә,
1 чокыр су.










**1.** Иң элек сөтне газда җылытырга куябыз. Ул кул пешмәслек кенә итеп җылынган арада куәс чиләгенә 0.5 л иссез көнбагыш мае, 3 йомырка, аш калагы белән 3 калак өеп шикәр комы, 1 аш калыгы өеп тоз, 1–2 калак майонез, бер чокыр җылы су салабыз. Шулар өстенә җылынган сөтне өстибез һәм 100 г лы чүпрәне салабыз. Чүпрә үз эшен эшли тора.

**2.** Ул вакытка инде безнең 2 шәр кг лы ике кап оныбыз иләнгән була. (Аның барысын да куәскә салып бетермибез, аның күпмесе-дер кала.) Камырны куерак итеп куәс чиләгендә ясыйбыз – онны аз-азлап салып камыр кашыктан төшәр-төшмәс булганчы 5–10 минут туглыйбыз.

**3.** Мичне ягып җибәргәч, куәс чиләген мич кырыена куябыз, камырыбыз шунда күмер төшкән арада кабарып менә (онытып җибәрсәң, ташырга да мөмкин). Табаларны янган мич кырыена җылытырга куябыз һәм, күмер төшкәч, кисәү агачы белән күмерне мич түренә этеп, аның өстенә 1–2 утын өстибез.



**4.** Калын чүпрәкне майга манып, шуның белән табаларны сөртеп-майлап алабыз һәм пешерә башлыйбыз. (Пешереп бетергәнче шул бер тапкыр майланган чүпрәкне кулланабыз.)



**5.** Өстәлгә чүпрәк җәеп пешкән коймакларны шунда суытырга тезә барабыз, чөнки өсте-өстенә куйсаң ул басыла, сыйфаты китә. Пешереп бетергәч, акмайга әзрәк көнбагыш мае өстәп болгатабыз һәм коймакны майлап табынга бирәбез. Чын-чынлап туй табынының түрендә булырлык сый булды коймагыбыз!






**Ашларыгыз тәмле булсын!**

**Автор фотолары**

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
## 2026

### ИЮЛЬ

**3 июль**

Сәнгать белгече, профессор Пётр Евгеньевич Корниловның тууына 130 ел (1896–1981). Ул 1920–1930 елларда ТАССРның Үзәк музеенда эшләгән.

**6 июль**

Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының сәнгать җитәкчесе, дирижёры, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Анатолий Иванович Шутиковка 80 яшь (1946).

**19 июль**

Тел галиме, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, ТАССРның, Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Диләрә Гариф кызы Тумашеваның тууына 100 ел (1926–2006).

**22 июль**

Татарстан Рәссамнар берлеге оештырылуга 90 ел.

### АВГУСТ

**1 август**

Археолог, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фаяз Шәриф улы Хуҗинга 75 яшь (1951).

**5 август**

Рәссам, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Надир Усман улы Әлмиевкә 80 яшь (1946).

**15 август**

Театр һәм гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, педагог, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Әнвәр кызы Җәмиловага 75 яшь (1951).

**16 август**

Тел галиме, тюрколог, филология фәннәре докторы, профессор, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның тууына 100 ел (1926–2008).

**17 август**

Казан һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең тантаналы ачылуына 140 ел (1886).

**23 август**

Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Михаил Иванович Кузнецовка 80 яшь (1946).

Актриса, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Дания Нургаяз кызы Нуруллинага 80 яшь (1946).

**29 август**

Тарихчы, педагог һәм җәмәгать-сәясәт эшлеклесе Һади Мифтахетдин улы Атласи (Атласов)ның тууына 150 ел (1876–1938).

### СЕНТЯБРЬ

**3 сентябрь**

Тел галиме, язучы, филология фәннәре докторы, профессор, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Илдар Мәлик улы Низамовның тууына 90 ел (1936– 2022).

**16 сентярь**

Язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Атилла Кадыйр улы Расихның (Рәсүлевнең) тууына 110 ел (1916–1996).

**21 сентябрь**

Казан университетының В.П.Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясе ачылуга 125 ел (1901). 2013 елда Планетарий эшли башлый; 2021 елда В.П.Энгельгардтның астрономия обсерваториясе музее ачыла; 2023 елда ЮНЕСКО Казан шәһәр астрономия обсерваториясен һәм В.П. Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясен Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертә.

**29 сентябрь**

Актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның, РСФСРның, СССРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәлил Гали улы Әбҗәлиловның тууына 130 ел (1896–1963).

https://kitaphane.tatars tan.ru сайтыннан алынды



**Кадерле укучыларыбыз!**
2026 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 468 сум 51 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 937 сум 02 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!

